Научно-практический журнал
1 (31) 2011

# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фәнни-гамәли журнал

# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК




## Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА – 125 ЕЛ

## 125 ЛЕТ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ Г. ТУКАЯ

## Татарстан Республикасы Президенты Указы
## Татарстан Республикасында 2011 елны Габдулла Тукай елы дип игълан итү турында

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай истәлеген һәм иҗади мирасын мәңгеләштерү максатларында, аның илебез һәм дөнья мәдәниятенә керткән зур өлешен исәпкә алып, шулай ук 2011 елда аның тууына 125 ел тулу уңаеннан карар бирәм:

1. Татарстан Республикасында 2011 елны Габдулла Тукай елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына элек үзе кабул иткән хокукый актларны әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Габдулла Тукай елын уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм урындагы массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Габдулла Тукай елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**Р.Н. Миңнеханов**
**Казан, Кремль 2011 ел, 11 февраль**

## Указ Президента Республики Татарстан
## Об объявлении 2011 года Годом Габдуллы Тукая в Республике Татарстан

В целях увековечения памяти и творческого наследия великого татарского поэта Габдуллы Тукая, учитывая выдающийся вклад, внесенный им в отечественную и мировую культуру, а также в связи с исполняющимся в 2011 году 125-летием со дня его рождения постановляю:

1. Объявить 2011 год Годом Габдуллы Тукая в Республике Татарстан.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои ранее принятые правовые акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, необходимые для его реализации.

3. Предложить главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан, общественным объединениям и организациям принять активное участие в проведении Года Габдуллы Тукая в Республике Татарстан.

4. Республиканскому агентству по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа», ОАО «Телерадиокомпания «Новый век», республиканским и местным средствам массовой информации обеспечить широкое освещение проведения Года Габдуллы Тукая в Республике Татарстан.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент Республики Татарстан Р.Н. Минниханов**
Казань, Кремль
11 февраля 2011 года

## БУ САНДА:
## В НОМЕРЕ:


*М. Низамиев.* Шигърияте дөньяны пакьләде ........ 2
*М. Низамиев.* Поэзия, облагородившая мир ........ 4

**РЕСПУБЛИКА КИТАПХАНӘЛӘРЕНДӘ**
**В БИБЛИОТЕКАХ РЕСПУБЛИКИ**
*Л. Фәретдинова.* Тукай рухы – халык күңелендә ........ 6
*А. Зәкәрова.* Тукайга тугры калып ........ 7
*Р. Камбиева.* «Тукай үлемсезлеген син озайтырга бурычлы» ........ 9
Без бәхетле, без шагыйрьле халык,
Без Тукайлы халык мәңгегә! *(телевикторина)* ........ 12
*Р. Фәизова.* Тукай исеме мәңгелек (әдәби-музыкаль кичә сценарие) ........ 14

**ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН**
**НАСЛЕДИЕ**
*Р. Мәрданов.* «Сөекле шагыйремез Тукайга ядкәр» ........ 16
*Л. Гобәйдуллин.* Габдулла Тукай мирасы ........ 18
*Г. Эркаева.* «Родной язык спасает жизнь» ........ 23

**ИСТӘЛЕКЛЕ ВАКЫЙГАЛАР**
**ЗНАМЕНАТЕЛЬНЫЕ ДАТЫ**
*Г. Җомаголова.* Габдулла Тукай китаплары Татарстан Республикасы
Милли китапханәсе фондларында ........ 24
*Ф. Имамова, А. Фәйзова.* Һәр буынга яшьтәш Тукай (әдәби-музыкаль кичә) ........ 27

**ҺӨНӘРДӘШЛӘРЕБЕЗДӘ**
**У НАШИХ КОЛЛЕГ**
*М. Мун.* Торжества по случаю 125-летия со дня рождения Габдуллы Тукая
в Донской государственной публичной библиотеке ........ 30

**АКТУАЛЬ ТЕМА**
**АКТУАЛЬНАЯ ТЕМА**
*Х. Борһанова.* Тел язмышы безне дә борчый ........ 32

**ЮБИЛЕЙЛАР**
**ЮБИЛЕИ**
Татарстан Республикасы муниципаль китапханәләре җитәкчеләрен котлау ........ 34

**БИБЛИОГРАФИК КҮРСӘТКЕЧ**
**БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЙ УКАЗАТЕЛЬ**
*Г. Сәйфуллина.* «И мөкатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз…»
(Г. Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан) ........ 35

**ТАТАРСТАН КИТАПХАНӘЛӘРЕ ХАКЫНДА ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ**
**О БИБЛИОТЕКАХ ТАТАРСТАНА В ПЕРИОДИЧЕСКОЙ ПЕЧАТИ** ........ 39

**ӘДӘБИ СӘХИФӘ**
**ЛИТЕРАТУРНАЯ СТРАНИЦА**
2011 елгы Г. Тукай премиясе лауреатлары әсәрләреннән үрнәкләр ........ 42

**ВАКЫТ-ВАКЫЙГА**
**ХРОНИКА**
*Ф. Вәлиева.* «Азатлык һәм гаделлек җырчысы»
(Г. Тукайга багышланган китап күргәзмәсе) ........ 34
*Г. Мадиярова.* «Мәгълүмат көне»
(Туфан Миңнуллин – Г. Тукай премиясе лауреаты) ........ 44
*Т. Рудик.* Юбилею Г. Тукая посвящается ........ 45
Ел китабы-2009 = Книга года-2009 ........ 47
Китапханәләр арасында «Лидер» кем? ........ 48

**ЯҢА БАСМА**
**НОВОЕ ИЗДАНИЕ**
Полвека служения книге ........ 46

**КОНКУРСЛАР**
**КОНКУРСЫ**
Иҗади бәйге ........ 46
Конкурс ........ 46

Приложение «Издательства и издающие организации» Республики Татарстан



# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

№ 1 (31) 2011

**ФӘННИ-ГАМӘЛИ ЖУРНАЛ**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан 1996 елның май аеннан башлап нәшер ителә. Елга 2 тапкыр татар һәм рус телләрендә чыгарыла.



Баш мөхәррир
**Р.И. ВӘЛИЕВ**

Редколлегия:
**Н.Ә. Камбеев,**
**С.Р. Җиһаншина,**
**И.Г. Һадиев**
(баш мөхәррир урынбасары),
**Р.Ә. Хөсәенова**
(җаваплы сәркятиб),
**Ә.Х. Мушинский,**
**А.Р. Габделхакова**
**А.Җ. Заһидуллин,**
**Х.Ш. Вәлитов**



# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК

№ 1 (31) 2011

**НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКИЙ ЖУРНАЛ**

Издается Национальной библиотекой Республики Татарстан с мая 1996 года. Выходит 2 раза в год на татарском и русском языках.



Главный редактор
**Р.И. ВАЛЕЕВ**

Редколлегия:
**Н.А. Камбеев,**
**С.Р. Зиганшина,**
**И.Г. Хадиев**
(зам. главного редактора),
**Р.А. Хусаинова**
(отв. секретарь),
**А.Х. Мушинский,**
**А.Р. Абдулхакова,**
**А.З. Загидуллин,**
**Х.Ш. Валитов**

# Шигърияте дөньяны пакьләде



Татар халык шагыйре, бөек классигыбыз, тәнкыйтьче, публицист, яңа заман татар теле һәм әдәбиятына нигез салучы Габдулла Тукайның (Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев) калын-калын томнарыннан, 2009 елда «Мәгариф» нәшрияты бастырып чыгарган, ике китаптан торган «Габдулла Тукай. Шигърият теле» сүзлегеннән безгә, килер буыннарга, калдырган биниһая кадерле һәм кыйммәтле мирасы белән яңадан танышып чыктым әле.

Үзе дә, җырлары кебек үк, «халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгесе» һәм мәңге сайрар сандугачы булган әдибебез моннан 100 ел элек Казанның Шәрык клубында халык әдәбияты турында бик тә хикмәтле сүзләр әйтә: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул».

Мостай Кәрим агабыз бик дөрес бәяләгәнчә, «моңа кадәр тарих белгән татарларның иң бөеге» булган, ЮНЕСКО карары белән дөньяның иң атаклы шәхесләре исемлегенә кертелгән сөекле шагыйребезнең тууына 125 ел тулуын билгеләп узабыз. Миңа, ярты гасырлык мәдәният һәм мәгариф өлкәсендәге хезмәт эшчәнлегенең соңгы биш елын Габдулла Тукайның Казандагы үзәк әдәби музеенда эшләүгә багышлаган ветеранга, Тукай аеруча кадерле. Шул уңай белән икенче мөхтәрәм классигыбыз Гаяз Исхакыйга мөрәҗәгать итәм. Ул Габдулла Тукайны, үзе исән чакта ук, «үлемсезлек бусагасын үткән чын халык шагыйре» дип олылый: «Тукай бар иде, Тукай бар, Тукай яши, Тукай яшәячәк, һәр үткән көн, һәр мәдәни атлаган адым Тукайны зур итәчәк, үстерәчәк кенә», – ди. Тукайсыз узган йөз елга якын гомеребез моны тагын бер кат раслый.

Тулыр-тулмас сигез еллык иҗат гомерендә Габдулла Тукай тарафыннан, галимнәр хисаплавы буенча, 10 меңнән артык шигырь юлын эченә алган 9 поэма, 400гә якын шигырь, баллада, җыр, бәет, мөнәҗәт, 350дән артык (50 табакка якын) проза әсәре: хикәяләр, истәлекләр, мәкаләләр, рецензияләр, репортажлар, фельетоннар, мәсәлләр, әкиятләр язылган. Шулар шагыйрьнең үзе исән чагында ук төрле зурлыктагы 35 китапта, ундарча газета-журналларда басылган. Бу иҗат үзенең зурлыгы, тирәнлеге, гомумкешелек дөньясының үткәне һәм бүгенгесе белән тыгыз бәйләнештә булуы белән таң калдыра.

Тукай иҗаты, аеруча шигърияте үзенә бер илаһи көчкә ия. «Бишенче елны бер көнне таң белән уянган» Тукай халкыбызның «хәсрәт көен көйләп» киләчәк өчен көрәшкә кушылган. Ул – үзенең иң беренче шигырьләренең берсендә үк: «Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; бу юлда һәртөрле хурлыкка, зарлыкка (авырлыкларга) түзмәккә», – дип, милләте, халкы өчен көрәшкә чакырган һәм соңгы сулышына кадәр аңа тугры калган әдип.

Габдулла Тукайның әдәби мирасы күптармаклы, киңкырлы. Аның үткен телле публицистикасын, камчылы сатирасын, кинаяле юморын, гаҗәеп матур лирикасын, гаҗәп тирән хикмәти, канатлы сүзләрен, тәнкыйть эшчәнлеген тагын бер кат өйрәнү, чор атмосферасын тою, хәзерге әдәбиятка Тукай принципларыннан чыгып бәя бирү тулаем әдәбиятыбыз, мәдәниятебез һәм сәнгатебез үсеше өчен, һичшиксез, файдалы булыр иде.

Күпчелек язучыларыбызга Тукай рухы, тукайлылык, үзенең татарына,

милләтенә фидакярләрчә бирелгәнлек җитми әле. Тукай, бүгенге хәйләкәр, яки артык акыллы кайбер шагыйрьләр, яки журналистлар кебек, һәрчак алдын-артын уйлап кына, теге якка да карап кына язган, иҗат иткән булса, гади бер рифмачы булып калыр иде. Власть башлыклары ни әйтер икән, теге кешенең кәефе кырылмас микән, бусы ачуланмас микән, дип яшәсә – бүген без сокланып укый, өйрәнә һәм олылый торган шәхес булмас та иде ул!

Һәм, әйтергә кирәк, үзенең соңгы шигырьләренең берсе булган «Кыйтга»да Тукай: «Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч…» дип юкка гына үзен кимсетә. Тукай бүләгенә лаек булган Рабит Батулла бик дөрес бәяли аны: «Сынмады аның кылычы, бетмәде аның көче, керләнмәде Тукай, бөек иҗаты, үлемсез шигърияте белән дөньяны пакьләп китте. Ул калдырган иҗат җимешләре менә йөз ел инде дөньяны чистарта, кешеләрнең күңелләрен яктырта».

Габдулла Тукайның иҗаты – бетмәс-төкәнмәс хәзинә. Мәгарифтә милли-төбәк компонентын бетерү турында Россия Дәүләт Думасы кабул иткән законны тормышка ашыру барган чорда бу турыда һич кенә дә истән чыгару ярамый. Гаяз Исхакыйның: «Бала мәктәптә вакытта беренче сыйныфтан башлап ахырына кадәр Тукайдан аерылмаска тиеш. Мәктәптә бала Тукай берлә бергә үсәргә, Тукай берлә егет булып мәйданга чыгарга тиеш». (Тукай мәктәптә//«Мәктәп» журналы. –1913 ел), дигән васыятен истә тотып, мәктәпләрдә һәм уку йортларында, ясле һәм балалар бакчаларында тәрбия эшен, татар теленә өйрәтүне, әдәби сөйләм культурасын үстерүне Тукай тормышы һәм иҗаты үрнәгендә оештыруның төгәл һәм тулы программасын төзергә кирәктер.

Татарның милли әдәби теленә нигез салучыларның берсе һәм иң бөеге булган Г. Тукай үз иҗатында һәр сүзнең мәгънәсен белеп кенә, үз урынында гына файдаланган. Шуңа күрә алар бөтен нурлары белән балкый һәм музыка булып яңгырый. Татар телен өйрәнүне нәкъ менә Тукайны, аның иҗатын өйрәнү белән бергә алып бара торган мәктәпләр әнә шуңа ота, мисемчә. Дөньяның иң бай дип исәпләнгән 14 теле арасына кергән татар телен өйрәнгәндә, Тукай теленең мөмкинлекләренә, иксез-чиксез байлыгына, никадәр канатлы кәлимәләр, гыйбарәләр-афоризмнар, мәкальләр, әйтемнәр булуына сокланмый мөмкин түгел. Бу мәсьәләдә мин үзем Галиҗәнап китапның роле зур дип саныйм, электрон әсбапларның мөмкинлекләре азрактыр дигән фикердә торам.

Сөекле шагыйребезнең 125 еллык юбилее – Татарстан һәм барлык күпмилләтле Россиядә, төрки һәм шәрык дөньясы мәдәни тормышында күренекле вакыйга. Ул бөтен дөнья буйлап зурлап билгеләп үтелә. Тукайны һәм аның кебек шәхесләребезне халыкара мәйданга күтәреп чыгу кирәктер. Шуннан башка татар милләтен таныту, үстерү мөмкин дә түгел. Бу көннәрдә халкыбыз аның Арча районы Кушлавыч һәм Кырлай авылларындагы, Казан, Уральск, Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләрендәге һәйкәлләренә чәчәкләр салалар, башкалабызның Яңа бистә зиратына, аның күпсанлы музейларына, газиз әтиәнисе җирләнгән Кушлавыч һәм Сасна Пүчинкәсе авылларына сәяхәт кылалар. Татар халкына «Туган тел» гимнын мөкатдәс мирас итеп калдырган шагыйребезнең туган көне милли бәйрәм, ана теле, шигырь һәм татар моңы бәйрәме буларак, республикабызда халыкара дәрәҗәдәге зур тантана итеп билгеләп үтелә. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасы янындагы мәйданда татар мәдәнияте символы булган Тукайга багышланган Шигърият бәйрәменә елдан-ел яңа бизәкләр өстәлә.

Шагыйрь яшәгән еллардан ераклашкан саен аның иҗатының бөеклеге, асыл мәгънәсе тагын да куәтләнә һәм тирәнрәк ачыла бара. Иҗатына караганда үзе дә төрек, гарәп, фарсы, казакъ, азәрбәйҗан, рус, татар телләрен яхшы белгән Тукай рус язучыларын, рус теле аша Көнбатыш, Шәрык язучыларын укыган, тәрҗемә иткән, алар иҗаты белән татар халкын һәм башка төрки халыкларны беренчеләрдән булып таныштырган. Шагыйрьнең үз шигырьләрендә башка халыкларның уртак тойгыларын гомуми кешелек сыйфатлары белән әйтә алуы һәм ул шигырьләрне кешелек ирешкән биеклеккә күтәрә алуы аны дөнья классиклары дәрәҗәсенә җиткерде.

Тукайның бөеклеге тагын шунда: ул үзенең иң әйбәт шигырьләрен балалар өчен язган. Ул аларның үз шагыйре, ул аларча сөйләшә, алар мохитендә яши ала. Аның гениаль сабыйлыгы әсәрдән-әсәргә күчеп, яңадан-яңа поэтик җәүһәрләр барлыкка китерә. Алар бүген дә үз кыйммәтләрен югалтмаган.

Реалистик һәм романтик рухтагы шигърияте ндә Тукай шагыйрьнең, әдипнең җәмгыятьтәге ролен бик югары бәяли: «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, тибрәтмәкче булсаң иң көчле кылларын, көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен, кирәк түгел, мәгънәсе юк, көлке, уен». Ул татар шигъриятенә яңа юллар ача, әдәбиятка җәмгыять исеменнән яңа бурычлар йөкли. Тукай өчен шигърият – ул яну-көю, гаделлек, хаклык өчен көрәш, теләсә нинди шартларда да вөҗданыңа, намусыңа тугры калу дигән сүз.

Тукай бер югары уку йортын да тәмамламаган, диссертацияләр якламаган, әмма аның тирән белемгә ия булуына гаҗәпләнми мөмкин түгел. Галимнәр бик дөрес бәяләгәнчә, чын мәгънәсендә даһи әдибебез үз иҗатында педагогикага, психологиягә, философиягә, сәясәткә, дипломатиягә, политэкономиягә, юриспруденциягә, журналистикага, хәрби белемнәргә мөрәҗәгать итә һәм тиешле фәнни югарылыкта фикерләвен күрсәтә.

Моннан күп еллар элек, халкыбызның уртак уй-хисләрен чагылдырып, олуг язучыбыз Әмирхан Еники болай дип язган иде: «Бер генә минутка фараз итик: безнең тарихыбызда Тукай юк, Тукай булмаган ди. Никадәр ярлыланып калыр идек без, күпме данд әрәҗәләребезне югалтыр идек!..». Әмма, язмышка рәхмәт, безнең Тукаебыз бар!

**Мөҗип НИЗАМИЕВ,**
*Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.*

# Поэзия, облагородившая мир

Недавно среди множества книг народного поэта, великого классика, критика, публициста, основоположника современного татарского языка и литературы Габдуллы Тукая мое внимание привлек двухтомный сборник издательства «Магариф» «Габдулла Тукай. Поэтический язык» (2009 г.), посвященный его бесценному творческому наследию.

Поэт, чье творчество нетленно и вечно, еще сто лет назад, выступая в Восточном клубе Казани, сказал о народной литературе следующее: «Народ велик, он могуч, он страстен, он музыкален, он писатель, он поэт».

Сегодня мы отмечаем 125-летие самого известного, по утверждению Мустая Карима, представителя татарского народа, чье имя занесено в книгу самых выдающихся деятелей планеты.

Для меня, как для человека, ветерана, полвека посвятившего себя служению культуре и искусству, проработавшему последние пять лет в музее Габдуллы Тукая, это имя особенно дорого. Поэтому я обраща-



юсь к другому классику татарской литературы – Гаязу Исхаки, который еще при жизни назвал Г.Тукая народным поэтом, перешагнувшим порог бессмертия: «Тукай был, Тукай есть, Тукай живет, Тукай будет жить. Каждый прожитый день, каждый шаг, сделанный нашей культурой, будет благодарен Тукаю и хранить память о нем». Сто лет, прожитые без Тукая, неоспоримо доказали это.

За неполных восемь лет творческой жизни Тукаем, по подсчетам ученых, было создано девять поэм, около четырехсот стихотворений, баллад, песен, баитов, мунаджатов, составивших вкупе более 10-ти тыс. поэтических строк, им написано более 350-ти прозаических сочинений: рассказов, воспоминаний, статей, рецензий, репортажей, фельетонов, басен, сказок. При жизни самого поэта было издано 35 книг сочинений, его произведения были опубликованы в десятках газет и журналов. Творчество поэта впечатляет своим объемом, глубиной, проникновенностью в общечеловеческие проблемы и связью с современностью.

В творчестве Г.Тукая, особенно в его поэзии, чувствуется божественная сила. «Проснувшийся в 1905 году» Тукай обратился в своем творчестве к теме борьбы за лучшее будущее своего народа. В одном из своих первых стихотворений он при-

зывал: «Пойдем на службу народу, будем трудиться в поте лица, не страшась различных трудностей». Поэт до последнего вздоха был верен этим словам.

Творчество Тукая разносторонне и многогранно. Сегодня в целом для современной литературы, культуры и искусства было бы очень полезно оценить их с точки зрения принципов Тукая, вновь обратиться к творчеству поэта, его эмоциональной публицистике, острой сатире, аллегорическому юмору, прекрасной лирике, ярким крылатым выражениям, литературной критике.

Многим современным писателям не достает высокого духа Тукая, такого же служения своему народу, нации, самоотверженности. Если бы Тукай, как некоторые предприимчивые писатели и отдельные журналисты, писал с оглядкой, то он стал бы заурядным литератором. Если бы он зависел от мнения властьимущих, боялся испортить отношения с некоторыми высокопоставленными персонами, мы бы сегодня не гордились его наследием и не имели бы такого великого человека.

Нужно сказать, что в своем последнем стихотворении «Кыйтга» Тукай бичует себя, утверждая, что силы его иссякли, а меч сломался… Лауреат премии Г.Тукая Рабит Батулла опроверг слова поэта, сказав так: «Не сломался его меч, не иссякли его силы, Тукай актуален, актуально его творчество, своим бессмертным творчеством он облагородил мир». Плоды его творчества вот уже более 100 лет облагораживают мир, освящают человеческие души…

Творчество Габдуллы Тукая – неиссякаемая сокровищница. В условиях, когда Государственная Дума РФ всячески стремится освободиться от национально-регионального компонента в образовании, об этом забывать никак нельзя. Девизом здесь могут стать слова Гаяза Исхаки о том, что творчество Тукая должно сопровождать школьника все годы обучения; о том, что ребенок должен расти и взрослеть вместе с Тукаем (Тукай в школе//Мәктәп. — 1913). Эти слова особенно актуальны при разработке различных программ в системе дошкольного и школьного образования и воспитания, обучении татарскому языку, формировании культуры разговорной речи и т.д.

Один из основоположников современного татарского языка Г.Тукай в своих произведениях очень ответственно относился к словам, употребляя их только в известных ему значениях. Именно поэтому тексты поэта так понятны и мелодичны. По-моему, выигрывают сегодня те школы, которые именно с творчества Тукая начинают изучение родного языка. Невозможно не восхищаться языком Тукая, поэтическим слогом поэта, афоризмами, прибаутками, красотой татарского языка, вошедшего в число 14-ти самых богатых языков мира. Я преклоняюсь перед ее величеством Книгой и считаю, что электронные издания заметно уступают ей по своим возможностям.

125-летие Г.Тукая – знаменательное событие для многонационального Татарстана и России, для культуры всего тюркского и восточного мира. Эта дата празднуется повсеместно и широко. Личности, подобные Тукаю, заслуживают быть признанными в мировом масштабе. Без обращения к имени Тукая невозможно позиционирование татарского народа как народа высокой культуры, народа с богатыми литературными традициями. В эти дни многочисленные памятники Тукаю в деревнях Арского района, Казани, Москве, Уральске, Санкт-Петербурге, Москве утопают в цветах, люди приходят почтить память поэта на старотатарское кладбище в Казани, музеи, могилы его родителей в деревнях Кушлавыч и Починок Сосна. День рождения автора гимна татарского народа «Туган тел» торжественно отмечается на международном уровне как День родного языка, праздник поэзии. На площади перед Татарским государственным академическим театром оперы и балета им. М.Джалиля, около памятника Г.Тукаю – символа татарской культуры – ежегодно собираются поклонники татарской поэзии.

Несмотря на то, что время, когда жил поэт, от нас постепенно отдаляется, его творчество до сих пор продолжает раскрываться все новыми и новыми гранями. Поэт, прекрасно владевший турецким, арабским, персидским, казахским, азербайджанским, русским языками, переводил сочинения русских писателей, знакомил татарских читателей и читателей других тюркских народов с творчеством западных и восточных писателей, тем самым объединяя эти народы.

Величие Тукая еще и в том, что свои лучшие произведения он адресовал детям. Он для них свой поэт, говорящий на их языке, прекрасно знающий детские интересы и проблемы. Его сочинения для детей и сегодня не потеряли своего значения.

В своей реалистической и романтической поэзии Г.Тукай высоко оценивает роль поэта в обществе, возлагает на поэта новые обязанности. Для Тукая поэзия – это горение, справедливость, борьба за интересы народа, совесть и честь. Невозможно не восхищаться Тукаем: человек, не имеющий высшего образования, не защищавший диссертаций, так разносторонне образован! Как справедливо отмечают ученые, поэт в своем творчестве обращается ко многим вопросам педагогики, психологии, философии, политики, дипломатии, политэкономии, журналистики, военного дела и демонстрирует при этом глубокие научные познания.

Много лет тому назад известный татарский писатель Амирхан Еники изрек такую мысль: «Только на минуту представьте себе: в нашей истории нет Тукая, его как бы и не было. Насколько бы мы обеднели, какое духовное богатство мы бы потеряли!» Однако спасибо судьбе, Тукай у нас есть!

**Музип НИЗАМИЕВ,**
*заслуженный работник культуры Татарстана и России*






# Тукай рухы – халык күңелендә

Һәр халыкның, һәр милләтнең йөзек кашы булырдай гүзәл шәхесләре, олы талантлары, бөтен кешелек дөньясы тарихында тирән эз калдырган затлары була. Бөек шагыйребез Габдулла Тукай, һичшиксез, әнә шундый олы шәхесләрнең берсе. Мәкаль, әйтем, канатлы сүзләргә әйләнеп киткән шигъри юллары, гимн вазифасын башкаручы «Туган тел»е, җир шарының бөтен халыкларын сокландырган «Шүрәле»се үзләре генә дә ни тора.

Һәр елның 26 апрелендә, олысыкечесе чәчәкләр тотып, Тукай һәйкәле янына килә. Тукайны олылый, аңа булган рәхмәтен белдерә. Быел бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулды. Төрки халыкларының мәдәниятен һәм сәнгатен үстерү буенча халыкара оешма – ТӨРКСОЙ – 2011 елны Тукай елы дип игълан итте.

Шул уңайдан барлык авыл китапханәләрендә бөек шагыйребезгә багышлап айлык һәм атналыклар, әдәбимузыкаль кичәләр, шигырь бәйрәмнәре һәм башка чаралар үткәрү планлаштырыды. Әлеге бәйрәмгә һәр китапханә үзенчә әзерләнә, Тукай иҗатын өйрәнүдә һәм аны халыкка җиткерүдә үз өлешен кертергә тырыша. Шагыйрьнең олы юбилее уңаеннан Сарман Үзәк китапханәсенең абонемент бүлегендә Г. Тукай әсәрләреннән, аның турындагы китаплардан оештырылган «Мәңге яши Тукай безнең күңелләрдә» дигән китап күргәзмәсе куелды. Аның янында «Моңлы саз чыңнары», «Тукай рухы – халык күңелендә» кебек әңгәмәләр уздырыла. Даими эшләп килүче әлеге күргәзмә матбугатта чыккан яңа язмалар һәм мәгълүматлар белән тулыландырылып тора.

*Эчем пошса, моңсулансам кайчак,*
*Тукайны мин алам кулыма.*
*Актаргалыйм аны әкрен генә*
*Тукталгалыйм кайбер юлына.*

Г. Тукай балаларда һәм яшьләрдә матурлык, әдәп, кешегә хөрмәт хисе тәрбияләүдә әдәбиятнең зур роль уйнавын белгәнгә «Сабыйларга гүзәл китаплар тәкъдим итегез!» – дип язып калдырган. Чыннан да, китап күңел үстерә, кәефне күтәрә, тормыштагы матурлыкны аңларга өйрәтә. Шагыйрьнең әсәрләре авырлыклардан курыкмаска, максатчан булырга, хезмәтне яратырга, бәхетле булырга өнди, белем алуга ихтыяҗны арттыра.

Г. Тукайның хәзерге көндә китапханәдә саклanучы 3 томлы сайланма әсәрләре, рус телендә басылып чыккан китаплары, шигырь җыентыклары, аның иҗатына күзәтү ясалган китаплар, Тукайның тормышына, иҗатына кагылышлы яңа басмалар укучыларыбызның күпсанлы сорауларына җавап табарга ярдәм итәләр.

Г. Тукайның шәхси тормышына багышлап уздырылган «Әйтелмәгән мәхәббәт» дип исемләнгән лирик кичә китап укучылар күңеленә хуш килде. Ул шагыйрь тормышындагы «яшерен мәхәббәтнең» ләззәтен һәм газапларын, Тукай биографиясенең укучыларга таныш булмаган битләрен ачып салды. Кичәдә Г. Тукайның әсәрләре һәм аның шигырьләренә язылган җырлар, шулай ук халык көйләре яңгырады. Укучыларга сәхнәләштерелгән тамаша күрсәтелде. Китапханәче Рәзинә Гарифуллина Зәйтүнә ролен бик уңышлы башкарды. Замандаш язучылары, дуслары арасында «Тукай Зәйтүнәсе» дип телгә кергән Зәйтүнә Мәүлүдованың тормышыннан кайбер мизгелләр турында сөйләнде. Г. Тукай иҗатына багышланган «Шагыйрьләр солтаны»- дип аталган китап күргәзмәсенә күзәтү ясалды.

Укучылар соравы буенча бу кичә Үзәк китапханәдә 2 тапкыр үткәрелде һәм район күләмендә оештырылган семинар көннәрендә авыл китапханәчеләренә дә тәкъдим ителде.

Әлбәттә, Г. Тукай иҗаты белән эшләү апрель ае белән генә чикләнми. Бу эш даими алып барыла.

**Лилия ФӘРЕТДИНОВА,**
*Татарстан Республикасы Сарман районы Үзәк китапханәсенең әйдәп баручы китапханәчесе*

***Статья освещает деятельность Сармановской центральной библиотеки по пропаганде творчества великого татарского поэта Габдуллы Тукая. В год 125-летия народного поэта в библиотеке состоялись театрализованные вечера, были организованы книжные выставки. И это только начало. Библиотекари Сармановской центральной библиотеки работают над новыми интересными проектами.***

# Тукайга тугры калып

Габдулла Тукай – татар әдәбияты күгендә янган якты йолдызларның иң зурысы, безнең мактанычыбыз һәм горурлыгыбыз. Әйе, горурланабыз, чөнки Бөек Тукаебыз нәкъ менә безнең якларда туып үскән, үзенең иң матур әсәрләрен безнең якларга багышлап иҗат иткән.

Аның исеме һәм язмышы мәдәниятебез тарихының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән мәңгегә бәйләнгән. Габдулла Тукай үз халкына, аның гореф-гадәтләренә, тел һәм мәдәниятенә тирән ихтирам белән карый. Аның әсәрләре туган халкына, туган җиренә чиксез мәхәббәтен чагылдыра торган гимн булып яңгырый.

Аның иҗаты – мәңге саекмас чишмә кебек. Тукай иҗаты үлемсез. Вакытлар узу белән әдәбият тарихында күп исемнәр тоныклана төшә, ә Тукай исә киресенчә, яңадан-яңа яклары һәм төсмерләре белән байый гына бара. Бүген без әдәбият, сәнгатьнең һәр тармагында ул чәчкән орлыкларның шытып чыгуын һәм чәчәк атуын күрәбез. Тукай чишмәсенә Арча җиренең бәрәкәтле туфрагыннан бәреп чыккан мул сулы башка иҗат чишмәләре дә кушыла. Алар: Татарстанның халык язучылары Гомәр Бәширов, Галиәсгар Камал, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, яраткан язучыларыбыз Мәрзия Фәйзуллина, Рафаил Төхфәтуллин, Радик Фәизов һәм башка бик күп әдәбият, сәнгать әһелләре.

Габдулла Тукайның «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дигән сүзләре нәкъ безнең Арча ягы халкына багышлап язылган диярсең. Дөрестән дә, районыбыз көннән-көн ныгый һәм матурая, аның мәгърифәте, мәгарифе, мәдәнияте, сәнгате һәм икътисады елдан-ел үсә.

Китапханәләребездә татар халкының горурлыгы булган Г.Тукайның иҗатын тирәнтен өйрәнү, аның шәхесе үрнәгендә яшь буынны тәрбияләү юнәлешендә эзлекле эш алып барыла. Китап күргәзмәләре төзегәндә, төрле кичәләр үткәргәндә без иң беренче аның китапларына мөрәҗәгать итәбез, цитаталарын, әдәби чагыштыруларын теләп кулланабыз. Чөнки аның иҗаты безгә бик якын һәм һәр өлкәдә алардан җавап табып була. Ә инде һәр елның апрель аенда бездә Тукай айлыгы игълан ителә. Китапханәчеләребез бу айлык кысаларында төрле чаралар үткәрәләр: Тукай белән бәйле урыннарга экскурсияләр, аңа багышланган иҗади бәйгеләр оештыралар. Апрель азагында Тукайның туган авылы Кушлавычта, ул яшәгән Яңа Кырлайда, Өчиледә һәм инде районыбыз үзәге Арча шәһәрендә Тукай бәйрәмнәре, берәүне дә битараф калдырмыйча, шаулап-гөрләп, зур әзерлек белән уздырыла. Алар Казаннан һәм Россиянең башка төбәкләреннән Тукайны зурлап килгән олы язучылар, сәнгать әһелләре белән очрашу һәм чын мәгънәсендә зур аралашу бәйрәме булып күңелләрдә уелып кала. Ирексездән шагыйрьнең «Бәйрәм бүген» дигән шигыре күңелләрдә кабатлана.

*«Бар күңелләлек бөтен дөньяда,*
*бар бер ямь бүген.*
*Нәрсәдән бу? – Мин беләм:*
*бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»*

Ул көннәрдә Арчабызның һәр тарафында Тукай рухы, шигъри рух хөкем сөрәдер сыман.

2011 елның, Тукаебызның юбилее уңаеннан, Татарстан Республикасында «Тукай елы» дип игълан ителүе безгә тагын да зуррак җаваплылык өсти. Бу елны матур һәм лаеклы итеп уздыру максатыннан районыбыз китапханәләре эшне махсус планнар нигезендә алып баралар. Ел башыннан барлык чараларны

Тукай исеме белән бәйләп үткәрәбез. Юбилей уңаеннан китапханәләр һәм клуб учреждениеләре арасында «Милләтемнең кояшы син, и моңлы, нурлы Тукай» дип исемләнгән сәнгать фестивале үткәрелде. Фестиваль кысаларында китап укучылар арасында яшь категорияләренә карап:

– Г.Тукай әсәрләрен сәнгатьле укучылар;

– Г.Тукай сүзләренә иҗат иткән халык һәм татар композиторлары җырларын башкаручылар;

– Татар халык музыка уен коралларында уйнаучылар һәм татар халык көйләрен башкаручылар;

– Г.Тукай әсәрләренә нигезләнеп сәхнәләштерелгән композиция күрсәтү;

– Татар халкының фольклор бизәкләре;

– Бөек шагыйрьнең әсәрләренә эшләнгән рәсем, кул эшләре, китап күргәзмәләре конкурслары уздырылды.

Фестивальнең I нче туры гыйнвар-февраль айларында һәр авыл җирлекләрендә, II нче туры март аенда зона ярышлары буларак үтте. Жюри һәр номинациядә иң лаеклы җиңүчеләрне билгеләде. Ә инде җиңүче лауреат, дипломантлар Арча шәһәрендә үткәрелгән Шигырь бәйрәмендә катнашты.

Билгеле, Г.Тукайга багышланган чаралар моның белән генә бетми. Һәр китапханәдә ел саен төрле китап күргәзмәләре, балалар иртәләре, әдәби кичәләр уздырылып тора. Китапханәчеләребез эш практикаларында Тукай иҗатын пропагандалауда яңа алымнарны да теләп кулланалар. Алар арасында: «Без Тукайны беләбезме?» дигән уен-викторина (балалар китапханәсе), «Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул» дигән сәхнәләштерелгән әкият-тамаша, «Шүрәледә кунакта» (Шүрәле поэмасы язылуга 100 ел тулуга багышланган әдәби кичә; балалар китапханәсе), «Тукай безнең йөрәкләрдә» дигән «Могҗизалар кыры» уены (Яңа Кишет авылы китапханәсе), «Без – Тукай шәкертләре» дигән балалар иртәсе (Иске Ашыт авылы китапханәсе) һ.б. Тукай атналыгы кысаларында китапханәләрдә «Тукайдан илһам алып» дигән баш астында яшь иҗатчылар конкурслары уздырыла. Шушы конкурслар нигезендә Яңа Кишет, Орнашбаш авыл китапханәчеләре үз авыл укучыларының иҗатын аерым китапчыклар итеп тупладылар. Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 1 нче филиалы оештырган Г.Тукайның портретлары күргәзмәсе һәркемне җәлеп итә һәм зур кызыксыну уята. Ә Яңа Кырлай авылы китапханәсе әзерләгән «Шагыйрь үткән сукмаклар» буйлап әдәби-музыкаль сәяхәте безне шагыйрьнең туган авылы Кушлавычка, балачагы үткән Кырлайга һәм Казан каласына багышлап язган әсәрләре дөньясына алып керә.

«Тукай геройлары әдәби паркы» проекты белән катнашып, Яңа Кенәр авылы китапханәсе Татарстан Республикасы хөкүмәте Грантына лаек булды. Парк Тукай иҗатын мәңгеләштерү, укучыларга якынайту максатыннан оештырыла. Г.Тукайның тууына 125 ел тулуны бәйрәм иткән көннәрдә паркны ачу тантанасы да булачак. Монда безне балачактан ук таныш булган Былтыр, Шүрәле, Су анасы һәм Кәҗә белән Сарык сыннары каршы алачак.

Г.Тукай үзе күпкырлы, кабатланмас шәхес булган кебек аның иҗатын укучыларга тәкъдим итү алымнары да күптөрле һәм һәрвакыт яңарып тора. Китапханәләребез, заман технологияләрен кулланып, презентацияләр ясыйлар, слайд-викториналар үткәрәләр. Әле яңа гына районыбызда Габдулла Тукайга багышланган Интернет-сайтны тәкъдир итү кичәсе булып үтте. Кичәдә әлеге проектның җитәкчесе Ә.Миңнуллина, сайтның әйдәп баручы хезмәткәре Л.Гаделшина тамашачыларны сайтның әһәмияте, төзелеше, бүлекләре белән таныштырдылар. Бу сайт безгә, китапханәчеләргә, Тукаебызның иҗатын укучыларга җиткерүдә тагы да киңрәк мөмкинлекләр ача.

Г.Тукай әсәрләре бүген дә безнең белән. Алар безне алга өнди, җанны сафландыра, өмет өсти, киләчәккә юл күрсәтә.

**Алсу ЗӘКӘРОВА,**
*Татарстан Республикасы Арча районы Үзәк китапханәсенең методик бүлеге мөдире*

***Для Арской центральной библиотеки 2011 год – год Г. Тукая – особенно знаменателен. Жители района гордятся тем, что являются земляками великого поэта. Талантливая арская земля дала республике такие имена, как, Гумер Баширов, Галиаскар Камал, Гариф Ахунов, Мухаммат Магдеев, Марзия Файзуллина, Рафаил Тухватуллин и др.***

***Празднование юбилея поэта началось с проведения фестиваля искусств библиотеками и клубными учреждениями района. Фестиваль проходил в нескольких номинациях и в нескольких турах.***

***Помимо фестиваля были проведены детские утренники, шоу, викторины и др. А проект «Литературный парк героев Г. Тукая» Ново- Кунерской сельской библиотеки получил Грант министерства культуры Республики Татарстан.***

***Накануне юбилейных торжеств в Арской центральной библиотеке состоялась презентация сайта, посвященного Г. Тукаю.***

# «Тукай үлемсезлеген син озайтырга бурычлы»

Бу сүзләр — Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Зиннур Мансуровның «Бурыч» шигыреннән. Шагыйрьнең бу фикере белән килешмәү мөмкин түгел. Тукай ул — халкыбызның вөҗданы, тормышын рухи яктыртучы, татарның акыл көчен һәм хис-тойгы байлыгын үз иҗатында чагылдырган олы шәхес. Халыкның андый асыл затларга ихлас мәхәббәте заманалар узу белән дә сүнми, тормыш юллары, иҗатлары белән кызыксыну, аларны тулырак, тирәнрәк аңларга теләү бервакытта да кимеми. Әмма бу хисне даими үстереп тору зарур. Моның өчен һәрберебез, аеруча китапханәчеләр җаваплы.

Тарихы дүрт дистә ярым ел белән генә исәпләнсә дә, Түбән Камабызда олуг шагыйребезнең исемен бер урам, бер китапханә, бер профессиональ колледж һәм бер лицей йөртә. Әйе, безнең Тукай урамыбыз һәм шул урамда урнашкан Тукай исемендәге үзәк китапханәбез бар дип, түбәнкамалылар зур горурлык белән әйтә ала. Горурланыр өчен җирлек бар. Биш катлы йортның пыяла һәм бетоннан салынган беренче катында урнашкан һәм ачылганда ук — 1972 елның салкын декабрь аенда — шәһәр җитәкчеләре тарафыннан Тукай исеме бирелгән китапханәбез 38 ел инде олуг татар шагыйренең бай иҗади мирасын шәһәрдәшләребезгә җиткерү белән шөгыльләнә.

Җиде-сигез елдан артмаган иҗат гомерендә Тукай 400ләп шигырь, баллада, поэма, 350ләп фельетон, публицистик мәкалә, әдәби тәнкыйть язмасы, рецензия, балалар өчен прозадагы миниатюра язып бастыра. Алар китапларга кереп, китапханәләр фондында лаеклы урын алды.

Татарстан Милли китапханәсе 2005елда «Габдулла Тукай» исемле методик ярдәмлек төзеде. Анда безнең Үзәк китапханәнең эш тәҗрибәсе, Тукай әсәрләре һәм, гомумән, татар фонды тупланунның беренче адымнары җентекләп язылган.

Алар хакында сөйләп тормыйбыз, ә шулай да, дөнья әдәбияты тарихында иң аянычлы язмышлы шагыйрь Г.Тукайның 125 еллык юбилее уңаеннан үткәрелгән кайбер чараларга туктальір алдыннан, фондыбызны баеткан китап һәм дисклар коллекциясе турында әйтеп китү урынлы булыр. Беренчесе – «Габдулла Тукай». Татарстан китап нәшриятында 2009 елда дөнья күргән бу китапка Г.Тукайның гасыр кичкән иң яхшы шигырьләре һәм чәчмә әсәрләре, шулай ук аларның рус телендә басылган тәрҗемә үрнәкләре туплап бирелгән. Системаның китап эшкәртү бүлегенә 2010 ел ахырында килгән бу китап зур зәвык белән, искиткеч матур бизәлгән. Даһи Тукайга лаек, эчтәлеге белән кыйммәтле китап! Икенчесе – Татарстанның мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү максатыннан «Вамин» фонды ярдәмендә чыгарылган «Габдулла Тукай» исемле коллекция, ул 4 дисктан тора. Әйтергә кирәк, бу электрон басмалар бүгенге чор таләпләренә туры килә һәм замана кулланучыларының ихтыяҗына җавап бирә.

Үзәк китапханәдә үз эченә 790 документ турындагы библиографик тасвирламаны сыйдырган, «Габдулла Тукай» дип аталган электрон картотека барча яңа материаллар турында тулы мәгълүмат бирә. Быел аның нигезендә «Иң бөек татар Габдулла Тукай» исемле 4 бүлектән торган (басылган мәкаләләр – 163 язма; сценарийлар – 57 язма; шагыйрьгә багышланган шигырьләр – 63 язма; җырлар – 6 язма; Тукай в русских изданиях – 23 язма) библиографик күрсәткеч төзелде.

Юбилей елы, алдагы еллардан аермалы буларак, Тукай айлыгы белән түгел, ә Тукай икеайлыгы белән башланып китте. Март аеның һәр көнендә мәктәп укучылары өчен «Тукай урамында, Тукай исемендә» дигән тематик экскурсия үтте. Моның өчен, мәгариф идарәсенең мәгълүмати-методик бүлеге аша, һәр мәктәпкә электрон почта буенча чакыру-игъланнар җибәрелде. Нәтиҗәдә, 500гә якын яшьләр һәм яшүсмерләр, алар арасында үзәк китапханәдән еракта урнашкан мәктәпләрдән дә укучылар, экскурсиягә килеп, үзләре өчен күп мәгълүмат алып китте. Алар китапханә тарихы, Тукайның китап тупламалары, яңа күргәзмәләр белән таныштылар. Экскурсия барышында мультимедиа җайланмалары да эшкә җигелде: экранда китапханә тарихын чагылдырган фотолар, уздырылган чаралар мизгелләре, телгә алынган китапларның тышлыклары күрсәтелде. Тукайга багышланган 8 сәгатьлек альбом-дисктан өзекләр дә бирелде.

Югарыда яңа күргәзмәләрне телгә алып үткән идек. Шуларның берсе – скульптура композициясе күргәзмәсе. Түбән Каманың танылган скульпторы

Рәис Сафин тарафыннан ясалган «Тукай һәм Шүрәле» скульптура композициясе авторның шәхси җыелмаларыннан вакытлыча кулланыр өчен сайлап алынды һәм Р.Сафинга багышланган материаллар янәшәсендә урнаштырылды. Бу күргәзмә китапханәдәге уку залының «Милләтемнең кояшы син, и моңлы, нурлы Тукай» исемле Тукайга багышланган төп күргәзмәнең күркәм дәвамы булды һәм китапханәгә килгән һәркемнең игътибарын үзенә җәлеп итте.

Мәгълүм булганча, Г.Тукай очрашуларда, әдәби-музыкаль кичәләрдә катнашырга яраткан, үзенең дә оештыру эшенә өлеш керткәне булган. Габдулла Тукайның туган көне алды атнасында, Үзәк китапханә «Түбән Кама язучылары — Тукай исемендәге китапханә кунаклары» дигән даими цикл кысаларында, үз китапларын бастырып чыгарган һәм китапханәләргә бүләк иткән авторларны, башка лаеклы сәнгать әһелләрен кунакка чакыра. Китапханә кунагына — шагыйрьме ул, рәссаммы — Тукай иҗаты тәэсир итмичә калмый. Мәсәлән, татарның танылган шагыйре, гомеренең соңгы елларын Түбән Камада уздырган Рәшит Гәрәй (сүз уңаеннан, язучылар атналыгы аның иҗатына багышланган искә алу кичәсе белән башланып китте) үзенең «Халкыбызның күңел түрендә» шигырендә түбәндәгеләрне яза:

*Легендалар түгел, тормыш үзе*
*Бирми аны, бирми үлемгә.*
*Сүнмәс йолдыз булып калка Тукай*
*Халкыбызның күңел түрендә.*

«Кушлавычта» шигырендә исә Рәшит Гәрәй кечкенә Апушны шунда уйнап йөргәндәй күзаллый һәм:

*Ишетәм «Туган тел» тынмый,*
*Яңгырый очтан-очка.*
*Пар атында Тукай үзе*
*Кайта күк Кушлавычка* – дип тәмамлый.

Шәһәребез шагыйрәсе, балалар өчен иҗат итүче Рәмзия Вәлиева сабыйлар күңеленә үтеп керердәй бер шигырендә яз килүне Тукай белән бәйли:

*Бар табигать шагыйрь бүген –*
*Урамда — Тукай язы.*

Бу юлларны Р. Вәлиеваның 2010 елда «Ихлас» нәшрият-полиграфия комплексында басылып чыккан «Бәхетле мизгелләр» дигән икенче китабыннан укып була.

Үзәк китапханәнең иң актив укучысы, ике шигырьләр җыентыгы авторы Нәфисә Баязитовага да Тукай китапханәсенең сәхнәсе бирелде. Республикакүләм «2009нчы ел китабы» конкурсының Түбән Кама буенча уздырылганында аның «Урман җыры» китабы иң күп әйләнештә булып, беренче урынга чыкты. Тукайга багышлап язган аерым шигыре булмаса да, барча шагыйрьләрнең нечкә күңелен аңлап, «Шагыйрьләр китә» шигырен яза:

*Шагыйрьләр китә, шагыйрьләр.*
*Китәләр асыл ирләр.*
*Үкенеч телә бәгырьне,*
*Шашып исәләр җилләр.*

*Язылмаган күпме шигырь,*
*Әйтелмәгән сүз китә.*
*Шагыйрь күңелен кем аңласын,*
*Ул бит җылы сүз көтә.*

*Калды бары китаплары,*
*Рәсемдә — моңлы күзләр.*
*Укыймын да хәйран калам:*
*Алтыннарга тиң сүзләр.*

*Табигать тә елый кебек,*
*Туктамый яңгыр ява.*
*Шагыйрьләр китеп баралар…*
*Күзләрдән яшьләр тама.*

Түбән Кама шәһәрендә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең бердәнбер лауреаты (1993) Әхсән Сәрим улы Фәтхетдинов яши. (Горурлык белән әйтәбез: Ташлык авылыннан Разил Вәлиев, Шәңгәлчедән – Зөлфәт Хәким дә — Тукай бүләге ияләре). Бүгенге татар Милли сәнгатен аның иҗатыннан башка күз алдына китерү кыен. Сәнгать белгечләренең дә, гади халыкның да фикере уртак: Әхсән Фәтхетдинов — уникаль сәнгать әсәрләре тудырган олуг рәссам. Агачка уеп ясалган декоратив бизәкләр, нәкыш сәнгате, агачтан ясалган декоратив скульптура сыннары, монументаль язу үрнәкләре — барысы да рәссамның кабатланмас талант иясе икәнен дәлилли. 1970-80нче елларда ул Тукайга багышланган байтак эшләр иҗат итә. Милли рухның, тарихи тамырның, газиз ана теленең мәңгелеген күрергә теләп, аны «Тукай Ватаны» дип атый. «Тукай — халык шагыйре», «Сак-Сок», «Тукай шигырьләре», «Сагыш», «Балачак хыяллары», «Тиздән апрель», «Көн ачыла», «Шигырь тууы», «Шүрәлеләрем», «Су анасы», «Мин китәмен» һәм, шулай ук, бик күп төрле Шүрәле образларын тудыра. Рәссам җаны гел Тукай тирәсендә әйләнә һәм ул шагыйрьнең юбилей елында халыкка әйтәсе сүзләрен, уй-фикерләрен үзенең шәһәр музеенда ачылган шәхси күргәзмәсендә, китапханәдә һәм ТЭЦ хезмәткәрләре өчен оештырылган очрашу-кичәләрендә җиткерде.

Роман Солнцев (Ренат Суфиев) – танылган рус язучысы. 30дан артык китабы меңләгән тираж белән СССР һәм Россия төбәкләрендә таралды, пьесалары Мәскәү, Красноярск һәм башка шәһәр сәхнәләрендә куелды, «Запомни меня такой» (режиссеры П.Чухрай), «Торможение в небесах» (режиссеры В. Бутурлин) фильмнарының һәм «Трое на красном ковре» телесериалының сценаристы, «День и ночь» әдәби журналының мөхәррире дә булган ул. Яшәешенең бер мизгелендә Р.Суфиев Тукайга үзенең тирән хөрмәтен белдерә. «Казан утлары» журналының 2009 елгы 4 санында Мөдәррис Вәлиевнең «Гыйбрәтләр аласы бар…» язмасында Солнцев-Суфиевның «На улице Тукая» дигән шигыре дә бирелгән:

*Что за поэзия такая,*
*что веет сквозь века светло?*
*Я жил на улице Тукая –*
*и мне, мальчишке, повезло.*
*Читал его стихи, мечтая*
*прославить камские края.*
*Теперь на улице Тукая*
*живут сестра и мать моя.*
*Да все мы – истина святая –*
*кто жаждет родине служить,*
*живет на улице Тукая*
*или хотя б мечтает жить!*

Роман Солнцев бу шигырен татар телендә дә күрергә теләгән. Шул исәптән, Англиядә яшәүче Равил Бохараевка хат аркылы үтенечен белдергән. Үз чиратында, Р Бохараев Мөдәррис Вәлиевкә мөрәҗәгать иткән. Соңгысы шигырьне тәрҗемә иткән. Күрәсең, тәрҗемә Р. Солнцевка ошаган һәм ул татар телендәге шигырен әнисе Салиха Мадьяровна Әхмәтовага җибәрүен сораган һәм адресын күрсәткән: «г. Нижнекамск, ул. Тукая». Шулай итеп, Роман Солнцевның тормыш җепләре Түбән Кама белән дә тоташа. Бу вакыйганы ничек игътибарсыз калдырасың ди инде?! Салиха Мадьяровнаны һәм Флера Харисовнаны эзләп табып, ике арада ныклы элемтә урнаштырдык һәм Тукай елында аларны китапханәгә чакырып, түбәнкамалылар белән таныштырдык. 2010 елда шәһәребездә чыга торган «Туган як» газетасында, нефтехимикларның «Хезмәттәш авазы» газетасында да табышыбыз турында мәгълүмат биргән идек.

Үзәк китапханә күп еллар Түбән Кама телерадиокомпаниясе белән тыгыз элемтәдә тора. Габдулла Тукайга багышланган иң отышлы чаралардан — «Без бәхетле, без шагыйрьле, без Тукайлы халык мәңгегә» дигән телевикторинаны атарга булыр иде. (Журналның 12-13 битләреннән карагыз.) 1995 елдан бирле 18 викторина үтте, шулардан 15е Тукайга багышланды. Телевикторина, Тукай иҗаты, аңа багышланган хезмәтләр белән таныштыру максатыннан тыш, халыкны китапханәгә килергә, андагы чараларда катнашырга да этәрә. Сорауларга әдәбият кулланмыйча җавап бирү җиңел эш түгел: викторина шартлары буенча да нинди чыганактан файдаланганны күрсәтү мәҗбүри таләп булгач, китапханәгә йөрмичә генә викторинада катнашу мөмкин түгел.

Безнең китапханә үз традицияләренә тугры калып, декламация белән мавыгучылар өчен инде 22нче мәртәбә сәнгатьле уку конкурсын уздырды. Конкурсның исеме өчен, якташыбыз Разил Вәлиевнең мәгълүм шигырендәге «Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен, шушы булыр иң зур бүләгең» дигән юлларын сайладык.

Тукай елы шәһәребезнең 45 еллыгына туры килү сәбәпле, конкурсантларның репертуары Түбән Кама авторларының иҗатына багышлап язылган шигырьләрен дә ярышка тәкъдим ителүен сорадык ... (the original line) 

ларның репертуары Түбән Кама авторларының иҗатыннан чыгыш ясаучының үзенең Г.Тукайга һәм, шулай ук, шәһәргә багышлап язылган әсәрләреннән торды. «…Шагыйрьгә матур шигырь язу читен. Әмма бер дә язмый тору аннан да читен диләр», — дип язган Г.Тукай Сәгыйть Сүнчәләйгә юллаган хатында. Түбән Каманың эшчән, талантлы халкы, күрәсең, иҗат итмичә тора алмый. Сәнгатьле уку конкурсының 2нче турында гына да төрле яшьтәге 160 кешедән 16сы үзе язганны сөйләде. Драматург Риза Ишморат әйтеп калдырган сүзләр белән килешмичә мөмкин түгел: «Шигырь!.. Әгәр яхшы шигырь булса, ул үзе генә дә укучыга, тыңлаучыга зур рухи азык һәм чиксез эстетик ләззәт бирә». Әйе, Тукай шигырьләрен тыңлаган саен тыңлыйсы килә, алардан туеп булмый! Һәр сөйләүче үз аһәңе, шигырьне аңлавы һәм тыңлаучыга җиткерә белүе белән аерылып тора. Әйтергә кирәк, бу циклдагы очрашукичәләрне Үзәк китапханә һәм шәһәр филиаллары әзерләп үткәрә. Быел Үзәк китапханә, Кол Гали исемендәге Милли китапханә, 2нче шәһәр, 7нче балалар китапханәләре атналыкны үткәрүгә зур көч куйдылар.

Үзәкләштерелгән китапханәләр системасында үткәрелгән һәр чарага тукталып тору мөмкин түгел, алар бик күп һәм барысы да кызыклы, мавыктыргыч итеп оештырылган. Формалары, эчтәлеге белән аерылып торалар. Апрель һәм апрель алды айларында китапханәләр дә яктырып, балкып китә. Татар теле, татар рухы уяна! Бар эшләгәннең кульминациясе, әлбәттә, Г.Тукай туган көндә — 26 апрельдә: ул көнне шәһәркүләм Шигърият бәйрәме үтә. 2011елда ул «И мөкатдәс моңлы сазым!»дип аталды. Г.Тукай исемендәге китапханә алдында 1991 елда урнаштырылган Тукай һәйкәле (сынчысы – Бакый Урманче) янында, көннең нинди булуына карамастан, кояшлымы, яңгырлымы, җиллеме, салкынмы, җылымы – бу Бәйрәм үтә. Китапханә хезмәткәрләре (1992–1998 елларда Камбиева Р. Г., 2007 – 2011 елларда Гыйбадуллина Г. Ш.) сценарий язып, оештыру эшләрендә актив катнашып, Бәйрәмне алып бардылар (Һадиева Г. К., Насыйрова А. З., Гыйбадуллина Г. Ш., Гыйльманов Л. И.).

Методик ярдәм мәсьәләсенә килгәндә, түбәндәгеләрне әйтеп китәргә була:

- методистлар тарафыннан һәр яңа методик материалга күзәтү үткәрелә, аерым формалар табылса, семинарларда, утырышларда һәм индивидуаль әңгәмәләр барышында җиткерелә, махсус әзерләнгән киштәләргә куела;
- һәр елның май аеның директор үткәрә торган Китапханә Советы утырышында, аерым бер мәсьәлә буларак, Тукай темасы буенча башкарылган эшләргә анализ ясала;
- 2011 елда «Бөек халкымның даһи улы» исемле фәнни-гамәли конференция узды. Конференциядә мәдәният һәм мәгариф идарәләренә караган китапханә хезмәткәрләре катнашты.

Күбрәк укыган, күбрәк эшләгән саен, Тукай безгә кадерлерәк була бара, аның тарихта тоткан урыны да, заманалар үтү белән, тагын да әһәмиятлерәк, олырак булып күренә.

**Рәмзия КАМБИЕВА,**
*Татарстан Республикасы*
*Түбән Кама шәһәренең Г.Тукай*
*исемендәге Үзәк китапханәсе*
*методик-библиографик бүлеге мөдире*

***В статье описан опыт работы Центральной библиотеки имени Г. Тукая г. Нижнекамска по пропаганде жизни и творчества великого татарского поэта Г. Тукая.***

***Среди форм работы тематическая экскурсия «На улице Тукая, именем Тукая»; выставка одной скульптуры (работа скульптора Раиса Сафина); цикл мероприятий «Гости библиотеки имени Г. Тукая»; телевикторина, проведенная совместно с телерадиокомпанией г. Нижнекамска, конкурс чтецов.***

***Кульминацией стал праздник Поэзии, проведенный 26 апреля.***

# Без бәхетле, без шагыйрьле халык,
# Без Тукайлы халык мәңгегә!

### (ТАТАРСТАННЫҢ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ҮЗӘК КИТАПХАНӘСЕ ТҮБӘН КАМА ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯСЕ БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ ҮТКӘРГӘН ТЕЛЕВИКТОРИНА)

**1. Вакыйф Нуриевның «Жиденче палата» (К.,2007) китабында «Шүрәле» хикәясе урын алган.**

**Сорау:** Бу хикәягә Тукайның ничә әкияте һәм ничә шигыре турында мәгълүматлар кергән?

**Җавап:** Язучы, бу хикәя-табышмагын язганда, Габдулла Тукайның «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрен, «Эш», «Ай һәм кояш», «Сабыйга», «Эш беткәч уйнарга ярый», «Эшкә өндәү», «Җир йокысы», «Гали белән Кәҗә» шигырьләрен күздә тоткан.

**Чыганак:** Вакыйф Нуриевның «Җиденче палата».–К.,2007.

**2. «Мәдәни җомга» газетасының 2010 нчы елгы өч санында (№ 16, № 20, № 21) шагыйрь Зиннур Мансуров «Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы» дигән басмада Г.Тукай белән әңгәмә алып бара.**

**Сорау:** XXI гасырда иҗат итүче шагыйрьнең Г. Тукай белән әңгәмә алып баруы мөмкин хәлме?

**Җавап:** Әлбәттә, турыдан-туры әңгәмә алып бару мөмкин хәл түгел. Әмма, зур аналитик эш алып барып, үз сорауларына җавапларны Тукайның 1-5 нче томнарында тупланган шигырь, проза, публицистика әсәрләреннән сайлап алып, Тукай сүзләре белән җавап бирә.

**Чыганак:** Мансуров З. Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы// Мәдәни җомга. – 2010. – №16, 20, 21.

**3. Шәһәребездә иҗат итүче бердәнбер мәсәлче Р. Шәйдуллин үзенең икенче китабын чыгаруга иреште. Китапка кергән мәсәлләр геройлары арасында Тукай персонажлары да очрый.**

**Сорау:** Әйтегез әле, Тукайның әкияти геройлары Рәфәт Шәйдуллин мәсәлләрендә нишлиләр? Мәсәлләрнең исемнәрен атагыз.

**Җавап:**
1 нче мәсәл: Мәсәл геройлары Яңа маҗараларга очрыйлар һәм Кәҗә белән Сарык Шүрәле-өрәкнең бармагын бүрәнә ярыгыннан чыгаралар (Шүрәле зур вәгъдәләр биргәч) әмма нәтиҗә: «Ит яхшылык – көт яманлык», – дип бик дөрес әйтелгән.
Бу мәсәлнең исеме «Кәҗә, Сарык һәм Шүрәле» (64 бит).

2 нче мәсәл: «Шүрәле һәм Су анасы» (70 бит). Аның язылуының төп максаты:

*«Ә инде укучым ятласын, дип.*
*Тукайның әсәрләрен,*
*Бөек шагыйрь хөрмәтенә*
*Язылды бу мәсәлем»*

**4. Туган туфрагыннан, рухи мирасыннан аерылган милләт вәкилләре вакытлар узу белән, Ватаныннан читтә, башка халыклар арасында йотылырга, йомылырга мәҗбүр. Бу хәл булмасын өчен мөһаҗирлектәге татарлар Тукай шәхесенә, иҗатына кат-кат мөрәҗәгать итәләр. Матбугат битләрендә әледән-әле моны раслый торган мәкаләләр басыла.**

**Сорау:** Татар эмигрантларының Тукайга багышланган истәлек язмалары аерым китап булып басылып чыктымы?

**Җавап:** Бөек шагыйребез турында татар эмигрантларының төрле матбугат органнарында басылган истәлек язмалары Зөфәр Мөхәммәтшинның «Ил йолдызы» китабына тупланган.

**Чыганак:** Мөхәммәтшин З. Г. Ил йолдызы: татар мөһаҗирләр матбугатында Габдулла Тукай /төз. З. Г. Мөхәммәтшин. — Казан: ТКН, 2006.– 190б.

**5. Г. Тукай тормышына караган аерым вакыйгалар һәм иҗаты белән бәйле даталар, фактлар, бәхәсле детальләр хроникаль яктан ачыклауны сорый. Шуңа да аның иҗат һәм тормыш елъязмасын төзү мөһим мәсьәлә булып калуын дәвам итә. Бу ихтыяҗны истә тотып, соңгы елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар һәм текстология бүлегеннән бер төркем хезмәткәрләр Тукайның иҗат һәм тормыш елъязмасын кабат күздән кичерү белән мәшгуль булдылар һәм әдипнең шәхси тормышына кагылышлы фактларны, вакыйгаларны, иҗади хезмәтен, һәр әсәренең язылу, басылу даталарын аның иҗат юлына тәңгәл килерлек итеп укучыга җиткерү белән шөгыльләнделәр. Әлеге эшнең нәтиҗәсе буларак гыйльми хезмәт барлыкка килде.**

**Сорау:** Классик шагыйребез Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы беренче тапкыр хронологик тәртиптә тәкъдим ителгән китапның исемен әйтегез.

**Җавап:** Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы/төз.Әнисә Алибаева, Фатыйма Ибраһимова.–Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.–271б.

**6. 1911 елның 6 нчы сентябрендә, нәкъ 100 ел элек, «Вакыт» газетасында Тукайның «Кадер кич» шигыре дөнья күрә.**

**Сорау:** Бу шигырьнең язылу тарихы турында мәгълүмат кемнең истәлегендә теркәлеп калган, ул нидән гыйбарәт?

**Җавап:** «Кадер кич» шигыренең язылу тарихы турында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Мансур Мозаффаров «Азат хатын» журналының 1988 елгы 4 нче санында истәлеген бастыра.

Ул түбәндәгечә яза: «Бервакыт әнием (Мөгаллимә, шагыйрә Маһруй Мозаффария) Тукайдан: Менә кадер кич җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы синдә, Габдулла? – дип сорады. Тукай берничә көннән безгә «Бу кадер кич, елда бер кич»дип башлана торган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка китерде».

**Чыганак:** Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан: ТКН, 2003.– Б.194-195.

**7. Сорау:** Әйтегез әле, 100 ел элек Г. Тукай үз туган көнендә ни белән мәшгуль булган?

**Җавап:** Г. Тукай Казаннан «Самолет» ширкәтенә караган «Тургенев» пароходының өченче классына утырып, Әстерханга сәфәргә чыга. Саратов шәһәрендә кызлар мәктәбенең бер төркем укучылары белән очраша. Кызлар аңа чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр. Тукай рәхмәт әйтеп «Тырышып укыгыз, халкыбыз өчен файдалы кешеләр булып үсегез», – ди.

Апрель азагында Әстерханга килеп төшә һәм анда 6 июньгә кадәр дуслары, танышлары һәм бирердәге интеллигенция белән аралашып яши. Иң элек дусты Сәгыйть Рәмиев янына – «Идел» газетасы редакциясенә килә. Шулай ук кымыз эчә, иҗат эше белән шөгыльләнә.

**Чыганак:** Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан: ТКН, 2003.– Б.179-180.

**8. «Инородческое обозрение» (1913, 3 нче сан) газетасында профессор Н. Ф. Катанов: «Шагыйрьнең үлеме бөтен халык өчен зур бер милли хәсрәткә әйләнде. Мәрхүм шагыйрьнең биографиясе һәм хатирәләр белән, шигырьләренең һәм талантының кыйммәтен тәкъдир итеп язылган мәкаләләр белән бөтен татар газеталары тулды», – дип яза. Мәсәлән, «Вакыт» газетасының 1913 елгы 30 апрель санында Семипалатинск шәһәреннән берәү шагыйрь исемен мәңгеләштерүдә беренче булып тәкъдим белән чыга.**

**Сорау:** Нинди тәкъдим була бу?

**Җавап:** Семипалатинск шәһәреннән «Вакыт» газетасына язган кеше Тукайга һәйкәл куярга кирәклеген белдерә.

**Чыганак:** Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы. – Казан, 2003.– 253, 255 б.

**9. Танылган рәссам Илдар Зарипов Г. Тукайның 100 еллык юбилеена багышлап «Шагыйрь туды» картинасын иҗат итә.**

**Сорау:** Илдар Зариповның «Шагыйрь туды» картинасының асыл мәгънәсен тасвирлап үтегез.

– Картина репродукциясен кайсы журналдан карый аласыз?

**Җавап:** Сөембикә. –2010.– № 4.– Б.1.

Бишектә асылташтай ялтырап бер мөлаем бала ята. Мичтәге кызыл күмернең уты, ананың якты чырае, баладан килгән нур – болар барысы да киләчәктә үзенең халкын дөньякүләм биеклеккә күтәрәчәк илаһи шагыйрь тууына ишарә.

**Чыганак:** Илдар Зариповның «Шагыйрь туды» картинасының репродукциясе «Сөембикә» журналының 2010 елгы 4 нче санының 1 нче битендә бирелгән.

**10. Сорау:** Түбән Кама шәһәрендә яшәүче кайсы скульптор Тукай иҗатына мөрәҗәгать иткән? Аның эшләрен атап үтегез.

**Җавап:** Тукай иҗатына мөрәҗәгать иткән скульптор – Рәис Рәүф улы Сафин. Аның гипстан ясалган «Тукай һәм Шүрәле» композициясе Үзәк китапханәдә оештырылган күргәзмәдә урын алган. Ә башка эшләрен ул шәһәр музеена бүләк иткән.

**Чыганак:** Моратова Ф. Җәлил һәйкәлен иҗат иткән скульптор//Туган як. — 2014.– 15 февраль.– Б.3.

# Тукай исеме мәңгелек

## (ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ КИЧӘ СЦЕНАРИЕ)

***Сәхнәдә Г. Тукайның зур портреты эленгән, портрет астында «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, тибрәтмәкче булсаң нечкә кылларын…» дип Тукай шигыреннән өземтә язылган.***

*Сәхнә ябык. «Тәфтиләү» көенә шигырь укыла.*

Тормышыңда бәйрәмнәр аз булган –
Тартыш белән тулган көннәрең.
Шуңа, ахры, искә алынмыйча
Үткән синең туган көннәрең...
Бәйрәмнәрең алда икән әле,
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп–
Халкың килде сиңа, мәхәббәтен
Ал чәчәкләр белән күтәреп.
Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап бүген туган көнеңне;
Киләчәккә барган улларыңнан
Ишетәсең «Туган тел»еңне.
Буын арты буын алмашынып
Гасыр арты узар гасырлар.
Шигърияте һәйкәленә шулай
Язлар һаман гөлләр ташырлар.
Халык моңы – синең моңың булды,
Халык күңеле – синең күңелең.
Ил гомере, халык гомере кебек
Озын булыр, шагыйрь, гомерең!

*Авыл күренеше. Бераз урман чите күренә. Яшьләр әкренләп кичке уенга җыела. Кызлар-егетләр көлешеп килеп чыгалар һәм сөйләшә башлыйлар:*

*Эльза:* – Кызлар туктагыз әле, Булат армиядән кайткан, бүген безнең янга килерме икән?
*Рәйнә:* – Нишләп килсен ди, аның Гөлназы монда юк бит…
*Галия:* – Әй, сөйләп торма әле, әнә Гөлназ килә. Гөлназ, Булатың кайткан бит, күрештегезме әле?
*Гөлназ:* – Куегыз сана, кызлар (*оялып кына*), күрештек бит инде…
*Эльза:* – Нәрсә, кайчан туй ясыйсыз?
*Гөлназ:* – Әй, аның турында сөйләшеп тормадык әле.
*Рәйнә:* – Кызлар, әнә куаклар арасында нәрсәдер кыштырдый…
*Галия:* – Ай, мин куркам…
*Гөлназ:* – Чын, тыңлагыз әле!..
*Эльза:* – Кызлар, Рамил бүген кемне озатыр икән?
*Лилия:* – Әй, аның бит Галиясе бар…
*Гөлназ:* – Аллам, нәрсә кыштырдый анда, ай…..(*Шүрәле чыга*)
*Рамил:* – Кети-кети уйныйбызмы, ә, кызлар????
*Галия:* – Кем бу, әнием, мин куркам…

*(Кызлар Шүрәлене урап алалар да җырлыйлар:)*

Җыр:

Җен дә түгел, җил дә түгел
Күренеп йөри торган.
Шүрәлене саклап тора
Татарда кара урман.
Шүрәле, Шүрәле,
Лилияне күр әле
Үзе бии,үзе җырлый,
Куллар чабып тор әле.

Бер мөгез дә, койрык бер,
Кети-кети уйный ул.
Кием-салым кими ул,
Балаларга тими ул.

Шүрәле, Шүрәле,
Гөлнараны күр әле.
Җырга оста, җырласын
Һич оялып тормасын.
Шүрәле ул беләдер,
Ул белгәнгә көләдер.
Пышылдый җил искәндә.
Рәхәт безгә үскәндә.
Шүрәле, Шүрәле,
Безнең янга кил әле.
Уртага чык та бие,
Килешеп тора көе.

*Лилия:* – Абау, бу бит Булат (*битеннән маскасын салдыралар*)

*Рәйнә:* – Сәлам Булат, нишләп безне куркытасың инде..?
*Рамил:* – Ай-яй, кызлар, җен белән бер икәнсез! Малайлар белән сөйләштек тә, куркытырга план кордык, табан ялтыратырсыз дип уйлаган идек… Ә сез? Ничек сезнең хәлләр, кызлар-йолдызлар? Тагын да чибәрләнгәнсез…
*Резидә:*

Һич сине куркытмасыннар
Шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз –
аларның булганы юктыр гомер.
Җен-фәлән дип сөйләшүләр
искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле –
шагыйранә ялган ул.
Һич өрәк, албасты булган
сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган
кара урман да юк.
Син әле үс һәм укы күп,
шунда аңларсын барын;
Мәгърифәт нуры ачар
күп нәрсәләрнең ялганын.

**«Сабыйга» шигыре.**

*Зөлфия:* – Сөйлә, Булат, авылны сагынып кайттыңмы, безне дә сагындыңмы?
*Рамил:* – Эх, кызлар, сагынмаган кайда инде ул… Мин дә Тукай шигыре белән әйтеп бирим әле:

Аерылып китсәм дә синнән
гомремнең таңында мин,
И Казан арты! сиңа кайттым
сөеп тагын да мин.
Ул таныш кырлар, болыннар
тартты әүвәл хисемми;
Тарта торгач, куймады,
кайтарды ахыр җисмеми.
Һәр фосулы әрбәгъәң:
язың, көзең, җәй, кыш көнең;
Барча, барча ак оек,
киндер, чабата, ыштырың!

Һәм көтүчең, этләрең,
үгез, сыер, сарыкларың;
Барчасы яхшы: бүре, җен,
Шүрәле, сарыкларың…

**Җыр: « Туган авыл»**

Тау башына салынгандыр
безнең авыл,
Бер чишмә бар,
якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен,
суын тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям
җаным-тәнем белән…

Истән чыкмый
монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап
гомер сөргәннәрем,
Абый белән бергәләшеп, кара җирне
Сука белән
ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки,
күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер: кая ташлар
бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам,
нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

*Гөлназ:* – Әй, кызлар-егетләр, әйдәгез әле, уен уйнап алыйк…

– Әйдәгез, йөзек салышлы уйныйбыз.

– Кемдә йөзек, сикереп чык… нишләтәбез?

*Бергә:* – Шигырь сөйләтәбез. (Нуртдинова Илсөяр, Түбән Каракитә авылының 10 сыйныф укучысы, Иске Чүпрәле 1 урта мәктәбенең 6 сыйныф укучысы Гадел Заһриев, Шланга авылыннан 9 сыйныф укучысы Назгөл Мәхмүтова Тукайга багышлап үзләре язган шигырьләрен укыйлар.)

Уен дәвам итә:

– Кемдә йөзек сикереп чык...

– Нишләтәбез?

– Җырлатабыз. Нинди җыр? Нинди, нинди, мәхәббәт турында инде. Тукайның да мәхәббәте булган ич, Зәйтүнәсе. Соң, әйдәгез, Зәйтүнәгә багышлап җырлыйк. (*Егетләр төркеме башкаруында җыр*).

– Кемдә йөзек сикереп чык.

– Нәрсә эшли белә, шуны эшләсен. (*Әтәч кебек кычкырырга*).

– Кемдә йөзек сикереп чык.

– Әкият сөйләтәбез… (Борын, борын заманда яшәгән ди бер патша, аның сарае булган таштан, сөйлимме яңа баштан?!..) Көлешеп уенны дәвам итәләр. Килеп керә узып баручы әби. (Гәләндәм Фәхретдинова, Иске Шәйморза авылыннан, пенсионер) һәм кызыгып шигырь укып китә.

– Кемдә йөзек сикереп чык.

– Биетәбез. (*Бергәләшеп биегәндә кызы Лилияне эзләп, әнисе килеп керә. Сәрия Хәлилова, 72 яшьлек пенсионерка, Яңа Кәкерле авылыннан*). Аңа шарт куялар, җырламыйча кызын җибәрмибез дип… һәм ул «Тәфтиләү» җырын башкарып кызын алып китә.

*Резидә:* – И кызлар, минем сеңел Тукай көнenә әзерләнәбез, репетиция ясыйбыз дип чыгып йөгергән иде… Әйдәгез, әкрен генә барып карыйбыз, нишлиләр икән?

Г. Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкиятеннән күренеш. (*«Бөтерчек» балалар театры*)

*Эльза:* – Бик кызык кыланалар, әйтерсең лә, чын артистлар...

*Галия:* – Әйдәгез, су буена кызлар...

*Рәйнә:* – И-и, су буенда Су анасы килеп чыкса тагын…

*Резидә:* – Әй, безгә тими ул, без бит аның алтын тарагын урламадык.

*Галия:* – Әкияттә генә диләр бит ул Су анасын, Шүрәлеләрне.

*Рәйнә:* – Әкияттә генә булыр ди, теге Түбән авылның Рәшит абый күргән бит. Бакырлыда Су анасын, шуннан бирле Бакырлыга борылып та карамый.

*Гөлназ:* – Сөйләмәле, ул елга буенда салып утырганда хатыны куркыткан диләр бит, шуннан башлап ул эчүен ташлаган һәм су буена бармый башлаган диләр.

*Эльза:* – Кызлар, бу кем? Ай, алтын тарак, Су анасы...

*(Барысы да йөгерешәләр, тарак тотып Рөстәм килеп чыга.)*

*Рөстәм:* – Кызлар-йолдызлар, менә курыктыгыз ичмасам. Тукай әкиятләре чынбарлыкка әйләнде бүген.

*Рамил:* – Кызлар-егетләр, төн булды бит инде, әйдәгез, иртән торып баздан бәрәңге чыгарасы бар бит әле, бәрәңге утыртыр вакыт җитте инде.

Менә мин сезгә бәрәңге турында Тукайның шигырен укып китим әле, сез көлеп эшләрсез иртән. (*Кулына зур бәрәңге тотып, шигырь укый*)

И бәрәңге! Безгә килдең
син ерак Америкадан,
Мәгърифәт! Син безгә килдең
мондарак, Европадан.
И бәрәңге! Син күрендең
әүвәле күрнешкә чит,
Шаулады, күргәч сине,
барлык мужик: ул, дип, «җәдит!»
И бәрәңге! Инде шатлан,
кичте баштан ул чагың,
Син, җиңеп иттең мәкян инде
мужикның корсагын.
Син кикертсәң, ул хәзер:
«Әлхәмделилла!» – дип куя;
«Күп шөкер, ди, бу җимешне
бирде мәула!» – дип куя.
Син алып үрнәк сабырлы
бу бәрәңгедән, гыйлем!
Аз гына нурландыра башла
мужикларның миен!

**«Бәрәңге вә гыйлем»**
**шигыреннән өзек.**

– Ай-һай, каты язган Тукай!

*(Бәрәңге турында җыр башкарыла)*

– Булды ди сиңа йодрык кадәрле бәрәңге былтыр, күгәрчен йомыркасы кадәр булды!

*Гөлназ:* – Алдагы елларда бәрәңгеләр дә, игеннәр дә мул булсын, уңышларыбыз мул булса, тормышларыбыз да күңелле, җырлы-биюле булыр. Алда да очрашулар насыйп булсын!

– Аллага шөкер, яхшы яшибез дуслар, күңелле яшибез. Бергәләшеп яшик, дус яшик, мондый күңелле бәйрәмнәрне сагынып искә алырлык итеп яшик дуслар!

*Резидә:* – Инде традицияне бозмыйк! Габдулла Тукайның тууына 125 елга багышланган бәйрәмебезне Тукайның «Туган тел» җыры белән тәмамлыйк!

**Ризидә ФӘИЗОВА,**
*Татарстан Республикасы*
*Чүпрәле районы Үзәк*
*китапханәсенең*
*баш китапханәчесе*

# «СӨЕКЛЕ ШАГЫЙРЕМЕЗ ТУКАЙГА ЯДКӘР»

Татар басма китабының тарихы искиткеч бай һәм, шул ук вакытта, серле дә. «Серле» дигәндә гарәп язуында нәшер ителгән һәм хәзер гыйльми китапханәләрдә саклана торган китапларны күздә тотабыз. Аларда шактый серләр бар әле. Ягъни, күренекле шәхесләребезнең милке булганлыгын, бүләк итеп бирелгәнне белдерә торган бихисап автограф-язмалар теркәлгән һәм күп санлы шәхси мөһерләр сугылган китапларның гыйльми әһәмиятләре бермә-бер югары.

Бездә әле мондый китаплар бөтенләй диярлек өйрәнелмичә кала бирәләр. Кыскасы, иске басма татар китапларындагы серләргә бай, мавыктыргыч тармак әлегәчә үз тикшерүчесен көтә. Тәгаен максат итеп, гыйльми нигездә эшкә тотынып, гыйльми китапханәләребез фондларындагы автографлы һәм мөһерле китапларның махсус каталогын әзерләү, һичшиксез, фән өчен изге гамәлләрнең берсе булыр иде. Татарстан Милли китапханәсендә бу эш алып барыла башлады инде.

Казан дәүләт университетының гыйльми китапханәсендә мондый серле һәм хикмәтле китаплар аеруча күп. Университетта белем алган студент елларымда кызыклы автографлар һ. б. мәгълүматлар теркәлгән китапларга еш юлыга идем.

Ул елларда күренекле татар халык шагыйре Габдулла Тукай исеме белән бәйле автографлы китаплар турында мәкалә дә язган идем (Тапшырылмаган ядкәрләр // Социалистик Татарстан. – 1991. – 31 май. – Б. 6). Еллар узгач, ун ел элек язылган бу мәкаләмә яңадан кайбер өстәмәләр килеп чыкты.

1990 елда Университет китапханәсендәге «Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре» исемле китаптагы автограф-язмага игътибар иткән идем. 1913 елда Казанда «Мәгариф көтепханәсе» нәшер иткән бу җыентыкның (китапның саклану шифры «Т 1010») беренче битендә, өстә «Сөекле шагыйремез Тукайга ядкәр. Мәдрәсәи «Мөхәммәдия» шәкертләреннән. 1913.4.4» дигән сүзләр каллиграфик нәфис итеп язылган. Мондый серле язмалы китапка тап булу куанычымны шул вакытта остазым Миркасыйм ага Госманов белән дә уртаклаштым. М. Госманов элегрәк шундый ук язманы китапханәдәге Ризаэтдин Фәхретдин китапларының берсендә күргәнлеген исенә төшерде. Эзләнүләр нәтиҗәсендә «Тукайга ядкәр…» дип язылган китап табылды. Әмма бер генә түгел, Университет китапханәсендә Р. Фәхретдиннең «Мөхәммәдия» шәкертләре исеменнән бүләк сүзләре язылган дүрт китабы (!) булганлыгы ачыкланды. Аларның икесе «Т 812» шифры белән саклананалар һәм бергә төпләнгәннәр. Китапларның берсе – Р. Фәхретдиннең «Ибне Гарәби» исемле, Оренбургта 1912 елда, икенчесе Р. Фәхретдиннең «Ибне Тәймия» исемле, Оренбургта 1911 елда нәшер ителгәннәр. Калган икесе – Р. Фәхретдиннең шулай ук бергә төпләнгән, «Т 814» шифры белән саклана торган «Көтебе ситтә вә мөәллифләре» (Оренбург, 1910) һәм «Әхмәд бай» (Оренбург, 1911) китаплары. Дүрт китапның да титул битләрендә шул ук истәлек сүзләре һәм шул ук дата теркәлгән.

Шәкертләр исеменнән язылган бүләк-ядкәр сүзләре янында күрсәтелгән «1913 елның 4 апреле» датасы баштарак аптырашта калдырган иде. Чөнки, мәгълүм булганча, Габдулла Тукай 1913 елның 2 апрелендә (иске стиль белән) дөнья куйган һәм 4 апрельдә җирләнгән. Ядкәр китапларындагы язмада 4 апрель датасы күрсәтелүе, әлбәттә, гаҗәбрәк тоелды. Әмма ядкәр китапларының тагын дүртесе табылгач, мәсьәлә бераз ачыкланды. Шәкертләрнең 4 апрельдә мәшһүр шагыйрь янына барырга җыенып, бүләк китапларын алдан әзерләп, истәлек язуларын да алданрак теркәп куюлары хакыйкатькә туры киләдер дигән фараз ныгыды. Болар хакында безнең тарафтан 1991 елда «Тапшырылмаган ядкәрләр» исемле мәкаләдә язылган һәм мондый китапларның тагын да булуы ихтимал дип белдерелгән иде.

Мәкалә газетада басылып, еллар узгач кына шуны белдем. «Казан утлары» журналының 1983 елгы 4 санында (179-180 битләр) Әбрар ага




▲ *Толстой Л. Хаҗи Морад. – Казан, 1913.*




▲ *Фәхретдин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре. – Оренбург, 1910.*




▲ *Фәхретдин Р. Ибне Гарәби. – Оренбург, 1912.*

Кәримуллинның Казан университеты китапханәсендә саклана торган, әмма югарыда әйтелгәннәрдән гайре бер китап турындагы, минем язмага охшаш, «Тапшырылмый калган бүләк» исемле мәкаләсе булган икән! Игътибарсызлыгым аркасында Әбрар ага мәкаләсен белми йөргәнмен. Ә. Кәримуллин белән аралашып, күрешеп торсак та, газетада минем язмам чыккач, ул да берни дә әйтмәгән иде. Ә инде мин «Казан утлары»ндагы мәкаләне үзем өчен «тапканда» Әбрар аганың сәламәтлеге бик какшаган булу сәбәпле, борчып йөрмәдем. Кыскасы, Әбрар абый да, мин дә бер үк мәсьәләдә (хәтта мәкалә исемнәре дә бер үк диярлек) язган булсак та, бу хакта арабызда әңгәмә-сөйләшү, кызганычка каршы, булмый калды.

Ә. Кәримуллин мәкаләсендә әйтелгән китап – Лев Толстойның «Хаҗи Морад» әсәре. Татарчага Мәхмүд Мәрҗани (Галәү) тәрҗемәсендә Казанда 1913 елда басылган. Бу китап Университет китапханәсендә «Т 958» шифры белән саклана. Титул битендә, югарыда «Мәдрәсәи «Мөхәммәдия» шәкертләре тарафыннан бөек шагыйремез Тукаевка ядкәр. 1913.4.4» дип язылган.

Язманың датасына нисбәтле фаразларыбыз аваздаш. Ә. Кәримуллин бу уңайдан «… бу китап шагыйрь кулына барып җитәргә өлгермәгән. Инде Тукайның вафаты бөтен Казанга гына мәгълүм булмыйча, ерак авылларга барып ишетелгән вакытта – дүртенче апрель көнне аңа шундый багышлама язу аңлашылмый. Мәсьәлә монда башкачарак булырга тиеш. Иң соң дигәндә, мөгаен, икенче апрель көнне «Мөхәммәдия» шәкертләре, сөекле шагыйрьләренең хәлен белү өчен, Клячкин больницасына барырга сүз куешалар һәм, шунда аңа бүләк итү максаты белән, әлеге китапны табып, махсус багышлама язалар. Язылу датасы итеп үзләре барачак көнне күрсәтәләр…» дип яза.

Шул рәвешчә, «Мөхәммәдия» шәкертләре исеменнән Тукайга бүләк итеп әзерләнгән китапларның ачыкланганнары алты булды.

«Тагын да шундый китаплар булмады микән?» дигән уй һаман күңелгә тынгылык бирмәде. Шәкертләр исеменнән шагыйрьгә бүләк ителергә ихтимал булган, 1910-1913 елларда татар телендә нәшер ителгән әдәби һәм фәнни китаплар даирәсен шартлы рәвештә тәгаенләп, эзләнүләрне дәвам иттек. Казан дәүләт университеты гыйльми китапханәсендәге йөзләгән китаплар тикшерелде. Нәтиҗәдә, бүләк язулы, «Т 797» шифры белән саклана торган, бергә төпләнгән янә ике китап ачыкланды. Аларның берсе Муса Бигиевнең «Халык нәзарына берничә мәсьәлә» исемле (Казан, 1912), икенчесе «Олуг кешеләр һәм аларның әсәрләре» (Казан, 1911; Монда Газиз Гобәйдуллинның һәм Нәҗип Хәлфиннең әдәби тәнкыйть мәкаләләре басылган). Бу ике китап та, башкалары кебек үк, яхшы итеп махсус тышлатылган булган. Беренчесенең тышлыгында, югарыда «Сөекле шагыйремез Тукайга ядкәр…» дигән мәгълүм сүзләр язылган. Китапларның икенчесендә шәкертләр исеменнән бүләк сүзләре язылмаган булса да, ике китап бергә, башкалары белән бер үк вакытта, нәкъ бер төсле үк рәвештә тышлап, төпләтелгән булуы – анысының да Тукайга ядкәр буларак әзерләнгәнлеген дәлилләп тора.

Шәкертләр бүләк өчен китапларны да зәвык белән сайлаганнар: күренекле әдипләрнең һәм галимнәрнең әсәрләре, хезмәтләре. Эчтәлек ягыннан да дөньякүләм мәшһүр ислам философларының тәрҗемәи хәлләре һәм эшчәнлекләрен тасвирлаган хезмәтләр, милләт өчен гаҗәеп күп көч һәм малын сарыф иткән мәшһүр татар сәүдәгәре Әхмәд бай Хөсәеневкә багышланган китап, әдәби әсәрләр,

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МИРАСЫ

## Шагыйрьнең Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана торган сирәк басмалары турында

***В статье кандидата филологических наук Р. Марданова повествуется о редких книгах с автографами, хранящихся в Научной библиотеке им. Н. И. Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета. Среди них были обнаружены восемь книг с памятными надписями шакирдов медресе «Мухаммадия», адресованных видному татарскому поэту Габдулле Тукаю. Однако эти книги так и не были ему вручены.***

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында Габдулла Тукайның алыштыргысыз дөньясы бар. Шагыйрьнең шәхесе һәм иҗаты инде менә бер гасырдан артык киң җәмәгатьчелекнең, әдәбият һәм сәнгать белгечләренең игътибарын үзенә җәлеп итеп килә. Җәлеп итмәслек тә түгел, чөнки Г.Тукай шигърияте үзе яшәгән һәм аннан соңгы дәверләрдә күп әдипләр өчен рухи маяк, илһам һәм акыл чыганагы булып торды: кемнәрдер аны күккә чөеп мактадылар, кемнәрдер тәнкыйтьләделәр, кайберәүләр үз шигъриятен аңа ияреп башлап җибәрде, иҗатында Тукай мотивларын, тема-проблемаларын дәвам итте, яңача ачты.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе Габдулла Тукай иҗатын өйрәнү, аеруча, аның әсәрләренең, китапларының төп нөсхәләрен саклау һәм халыкка җиткерү белән дә шөгыльләнә. Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклanучы, шагыйрьгә нисбәтле чыганакларны берничә төркемгә бүләргә мөмкин:

1) үзе исән вакытта дөнья күргән китаплары;

2) вафатыннан соң басылып чыккан китаплары;

3) чит илләрдә яшәүче татарлар тарафыннан нәшер ителгән китаплары һәм газета-журналларның шагыйрьгә мөнәсәбәтле нөсхәләре;

4) шагыйрь әсәрләренең кульъязма күчерелмәләре;

5) XX йөз башында Г.Тукай әсәрләре басылган вакытлы матбугат.

Бүлектә Г.Тукайның 26 исемдәге 40 тан артык басма китабы саклана. Шуларның 14 исемдәге китабы үзе исән вакытта дөнья күргән. Әлеге китапларның иң әүвәлгесе 1907 елга нисбәтле. Ул бертуган Шәрәфләрнең китап нәшриятында «Шигырьләр китапханәсе» сериясеннән 3 нче дәфтәр буларак, «Г.Тукай шигырьләре» исеме астында дөнья күргән. Шул ук елны бу сериядән шагыйрьнең 4 нче дәфтәре – «Габ-

әдәби тәнкыйть… Шунысы аяныч, Тукайның үлеме сәбәпле, шәкертләр аны бу кыйммәтле бүләкләре белән сөендерергә өлгермәгәннәр. Тик, шулай да, бу факт китапларның әһәмиятен киметми, һәрхәлдә, бу серле китаплар мәдәният тарихыбызда игътибарга лаеклы.

Халкыбызның бөек шагыйре Тукайга үз вакытында шәкертләр тарафыннан әзерләнеп тә, тапшырылмыйча калган китапларның безгә әлегә билгеле булганнары шул сигез берәмлек.

Һичшиксез, киләчәктәге эзләнүләр боларга охшаш башка кызыклы табышлар белән дә сөендерер әле. Чөнки, язмабызның башында әйтелгәнчә, мондый серле китаплар күп. Алар бары тик үз серләрен ачачак тикшерүчеләрне генә көтәләр.

**Раиф МӘРДАНОВ,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең редакция-нәшрият бүлеге баш китапханәчесе, филология фәннәре кандидаты*




▲ *«Жуаныч»*




▲ *«Энҗе бөртекләре»*



▲ *«Алтын әтәч»*

дулла Тукаев шигырьләре» исемле китабы басыла. Шулай ук китапханәдә Г.Тукайның, һәр елны диярлек, Казан шәһәрендәге «Мәгариф», «Сабах», «Үрнәк», «Өмет» матбагаларында нәшер ителгән китаплары бар. Алар «Г.Тукаев диваны» (1908), «Энже бөртекләре» (1909), «Күңел җимешләре» (1911) исемнәре астында дөнья күргәннәр. «Яшен ташлары» (1911) исемле җыентыкның кереш сүзендә бу китапны автор, «Башыңдагы чабата», «Матбугат клоуны» дип атарга теләвен белдерсә дә, 1908-1909 елларда нәшер ителгән «Яшен» сатирик, юмористик журналы хөрмәтенә җыйган «чүп-чарын» «Яшен ташлары» дип исемләвен әйтә. 1908 елда Г.Тукайның рус әкиятенә ияреп язган, «Сабах» китапханәсендә нәшер ителгән «Алтын әтәч» китабы балалар өчен төсле рәсемнәр белән бизәлгән китапларның матур үрнәге булып тора. 1910 елда нәшер ителгән «Халык моңнары» исемле җыентыкта шагыйрь халык җырларын җыючы буларак та таныла, чөнки аның бу китабында Казан трактирларыннан җыеп алынган җырлар тупланган (5, 86). Ә 1912 елда «Мәгариф» китапханәсе наширлегендә дөнья күргән «Җан азыклары» исемле җыентык шагыйрьнең үзе исән чакта басылып чыккан соңгы шигырьләр мәҗмугасы булып тора.

Г.Тукайның балалар тәрбияләүгә керткән өлеше бәһаләп бетергесез. Бер мәкаләсендә ул: «Бала тәрбияләүдә яхшы нәтиҗәләргә барып җитү өчен, иң элек баланың табигатен, әхлагын һәм йөреш-торышын нечкәлекләп белергә кирәк. Менә иң читене – баланың ошбу хасиятләрен аңламактыр… Баланың рухын бик ачык аңлау өчен, һаман аның хәрәкәтләрен күзләп, аның яхшы вә яман холыкларының һәммәсен дә аерып белергә тырышырга кирәк. Балага үзең теләгән рәвешне бирергә теләсәң, бик озак вакытлар чыдарга вә сабыр итәргә һәм акрын гына эш йөртергә тиештер», – дип яза (4, 233). Шагыйрьнең кайбер әсәрләре нигезендә басылган китаплар татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен уку әсбабы буларак та кулланылганнар. Мондый китаплардан «Балалар күңеле» сериясендәге «Мияубикә», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык», «Эшче» әсәрләре (1911, 1919 (2), 1921[1]) – безнең бүлектә саклаучы җәүһәрләрдән. «Яңа кыйраәт» (1910, 1915, 1918) исемле китапта шагыйрь әсәрләре алдыннан балаларны укыту методикасы турында кызыклы гына мәгълүматлар бар. Ә «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911, 1918) исемле дәреслек-хрестоматиясендә шагыйрь, үз иҗат җимешләре белән бергә, төрле әдипләрнең әсәрләрен туплап бастыра. Алар арасында Габдеррәшид Ибраһимов, Зариф Бәшири, Фатыйх Әмирхан, Нәҗиб Думави, Сәгыйть Рәмиев, Садретдин Максуди, Гаяз Исхакый кебек олуг әдипләребезнең әсәрләре бар. Бу хезмәтләре белән Габдулла Тукай мәктәптә татар әдәбиятын системалы рәвештә өйрәнә башлауга нигез сала. Вафатыннан соң да югарыда саналган китапларның берничә тапкыр басылуы аларга булган ихтыяҗ турында сөйли.

Үзе исән вакытта ук шагыйрь яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә, шулай ук балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләүдә, балаларның китап укырга кызыксынуларын үстерүдә үзеннән зур өлеш кертте.

Шагыйрь вафатыннан соң да аның иҗатын популярлаштыру эше дәвам итә. Шуның нәтиҗәсе буларак, Г.Тукайның югарыда искә алынган китаплары яңадан басылалар, шулар белән бергә «Шигырьләр китапха-

[1] *Җәяләр эчендә Милли китапханәдә шушы еллардагы басмаларның саклануы күрсәтелә.*

нәсе» сериясеннән яңа җыентыклары чыгуы дәвам итә. Китапханәдә шагыйрьнең «Әдәбият» (1917; «Шигырьләр китапханәсеннән» 10 нчы дәфтәр), «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» («Шигырьләр китапханәсеннән» 7 нче дәфтәр) кебек китаплары саклана. «Халык әдәбияты» (1917, 1919) җыентыгында шагыйрьнең 1910 елда «Шәрык» клубында халык җырлары турында укыган лекциясе урын алган.

1913-1929 елларда басылган, Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклanучы өч хезмәт аеруча игътибарга лаек. Аларның беренчесе Г.Шәрәф туплаган «Тукай сүзләре» (1913, 1914) дип аталган җыентык. Бередә Г.Тукайның халык арасында афоризмнарга әверелгән сүз-гыйбарәләре җыеп бастырылган. Тукай шигырьләре халык арасында шактый танылган. Бу турыда Г.Шәрәф түбәндәгеләрне яза: «Сүз арасында хатиблар (вәгазь сөйләүчеләр) сүзен ачыграк аңлатасы, я аны берәр нәрсәгә мөсәлләм итәргә (күндерергә) теләгән кешеләр агызыннан, дәлил урынына Тукаев шигырьләренең кисәкләре шактый ишетелгәлиләр, газета вә журналларда мәкалә язучыларыбыз да, Тукаев сүзләрен үзләренә ярдәмгә еш-еш чакыгалыйлар». Г.Шәрәф язуынча, киләчәктә Г.Тукайның күп шигырьләре татарлар арасында бабалар мәкале белән бер сафта йөртеләчәк.

Беренче тукайчы галим Җамал Вәлиди төзегән «Габдулла Тукайның мәҗмугаи асаре» (1914, 1918) дигән китап аеруча игътибарга лаек. Бу китапта «Г.Тукайның тәрҗемәи хәле һәм әшгаре (шигырьләре) хакындагы бер мөляхәзә (уйлану)» исемле язмасында галим, беренчеләрдән булып, Г.Тукай биографиясен, иҗат үсешен заман һәм чор белән бәйләп ачыклый, аның шигырьләренең идея эчтәлеген, форматөзелешен өйрәнә. Шагыйрьнең иҗади үсешен өч дәвергә бүлеп карый: 1905-1906, 1907-1909, 1910-1913. Мәкаләнең соңгы бүлегендә Җ. Вәлиди, Г.Тукай исән вакытта ук аның турында язылган мәкаләләрне, тәгъзия, мәрсияләрне хронологик тәртиптә туплый, анализлый (2, 78). Китап шагыйрь шәхесенә мөнәсәбәтле төрле фоторәсемнәр туплануы белән дә фәнни әһәмияткә ия. Без бу китап битләреннән Кырлай, Кушлавыч, Өчиле авылларының, төрле шәхесләрнең XX йөз башындагы фоторәсемнәрен күрәбез.

1926 елда нәшер ителгән, фәнни әһәмияткә лаек тагын бер китап – Ф.Бурнаш төзегән «Г.Тукай шигырьләре» китабы. Аның бер өлешендә Ф. Бурнашның шагыйрь биографиясенә нисбәтле күләмле мәкаләсе, төрле фоторәсемнәр урын алган.

1905 елдан «Фикер», «Таң йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы», «Әл-ислах» газеталары, «Әл-гасрел-җәдид», «Уклар» журналлары Г.Тукай өчен тәүге поэтик трибунага әверелә. Шагыйрь 1907 елның көзеннән Казанда «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын чыгаруда актив катнаша. Китапханәдә әлеге басмаларның кайбер нөсхәләре саклана.

Татар халкында Г.Тукай иҗатына булган ихтыяҗны аның басылып чыккан китаплары, газета-журналларда дөнья күргән шигырьләре генә канәгатьләндермәгән. XX гасырның урталарына кадәр, Г.Тукайның томлыклары басылып чыкканчы, аның шигырьләре халыкта кулдан-кулга күчерелеп таратылганнар. Г.Тукай шигырьләрен күчереп язган дәфтәрләр археографик командировка һәм экспедицияләрдә аеруча еш табылалар.

Милли китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Г.Тукай мирасын саклаучы тагын бер төркем чыганакларга тукталып үтү урынлы булыр. Ул татар мөһаҗирләре тарафыннан Г.Тукайның





▲ *«Габдулла Тукаев шигырьләре»*



▲ *«Халык моңнары»*



▲ *«Халык әдәбияты»*



▲ *«Печән базары яхуд Яңа кисекбаш»*



▲ *«Күңел җимешләре»*



▲ *«Җан азыклары»*



▲ *«Исемдә калганнар»*

Финляндия, Кытай кебек илләрдә бастырылган китаплары һәм Кытайда чыккан «Милли байрак» газетасының, Германиядә дөнья күргән «Яңа Милли юл», Төркиядә нәшер ителгән «Казан» журналларының шагыйрьгә нисбәтле сәхифәләре.

Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының Ерак Шәрыктагы дини-милли мәркәзенең мәгариф шөгъбәсе 1935-1945 елларда Мукден шәһәрендә нәшер иткән «Милли байрак» газетасында, нигездә, Г.Тукай иҗаты һәм шәхесе турында мәкаләләр, апрель аенда аны искә төшерүгә багышланган кичәләр турында мәгълүматлар урын алган. Гомумән, Кытайның Харбин, Мукден, Хайлар, Шанхай кебек шәһәрләрендә бер генә милли мәҗлестә Г.Тукай шигырьләреннән, аның моңнарыннан башка уздырылмаган. Гадәттә, Тукай кичәләре көндез балалар, кичен өлкәннәр өчен оештырылган. Шагыйрьне искә алу мәҗлесләре шәкертләр тарафыннан аның рухына Коръән уку белән башланып киткән. Мәҗлестә катнашучылар үзләренең кереш сүзләрендә туган якларны сагынуларын, киләчәктә анда кайтып гомер итү хыялы белән яшәүләрен белдергәннәр. Кичәләр Г.Тукай шигырьләрен уку, «Шүрәле», «Су анасы» кебек әсәрләрне сәхнәдә уйнау белән дәвам иткән. Өлкәннәр өчен үткәрелгән өлештә, шагыйрь шигырьләре укылу белән бергә, Тукай маршы, төрле милли көйләр уйналган. Чыгышларда Тукайның яратылышындагы төп сызык – кайгы һәм хәсрәт сызыгы булуына басым ясалган, һәм бу язмышны үзләренеке, туган илдән, туганнардан аерылып китеп, чит илдә ятим яшәү белән чагыштырганнар. Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең Әхмәдвәли Мәңгәр тупланмасында 1938 елда Мукден шәһәрендә Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу уңае белән басылган китап бар (Габдулла Тукай (1886-1913) / Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини-милли мәркәзе мәгариф шөгъбәсе. – Мукден, 1938. – 98 б.). Чит илдә үсә торган яшьләрне шагыйрь белән таныштыру өчен, Ерак Шәрыктә яшәүче Идел-Урал төрек-татар мөселманнарының дини, милли мәркәзе үзенең бишенче тулы утырышында шушы мәҗмуганы чыгару карарын кабул итә. Мәркәзнең мәгариф шөгъбәсе әлеге рисаләне тулырак нәшер итү өмете белән Тукайга караган материаллар, рәсемнәр юллауны сорап, Ерак Шәрыктә яшәүче мөһаҗир халыкларның зыялыларына махсус хатлар белән мөрәҗәгать иткәнлеге турында яза. Китапта Г.Исхакыйның «Шагыйрь Габдулла Тукай», Хөсәен Габдүшнең «Тукайны онытмау – милли бурычыбыз» исемле мәкаләләрендә шагыйрь шәхесе, аның бөеклеге турында языла, икенче өлештә Г.Тукайның танылган шигырьләре бирелә.

Гаяз Исхакый мөхәррирлегендә һәм наширлегендә 1928-1939 елларда Берлинда, Варшавада чыккан иҗтимагый-сәяси, фәнни әдәби «Яңа Милли юл» журналының шул ук 1938 елгы апрель санында Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу белән мөнәсәбәтле мәкаләләр урын ала. Аларда Г.Тукайны сагыну, аның иҗатының бөеклегенә дан җырлау, милләт язмышы һәм аның киләчәге турында уйлану кызыл җеп булып сузыла.

Бүлектә Финляндиядә 1966 елда нәшер ителгән «Татар шагыйре Габдулла Тукай» исемле җыентык та саклана (Габдулла Тукай: Татар шагыйре Габдулла Тукай. Шигырьләр. – Тампере, 1966. – 24 б.). Китапны төзүченең кереш сүзендә язылганча, Финляндия татарларында элек-электән мәшһүр шагыйрь Габдулла Тукай кичәләре, аны искә төшерү хатирәләре гадәт буенча һәр ел саен үткәрелеп килгәннәр. Әмма автор искәрткәнчә, хәзер (ягъни 1950-60 нчы елларда) мондый милли кичәләр аларда төштәгедәй генә булып

калган, урта яшьтәгеләр һәм аннан кечерәкләр үзләренең милли моңнарын, милли көйләрен һәм җырларын, башка гореф-гадәтләрен оныта башлаганнар, рухи яктан бөтенләй ярлыланганнар. Әлеге җыентыкның Финляндиядә басылып чыгуы да Тукай иҗатына сусау, аны сагыну, билгеле иҗтимагый шартларда килеп туган рухи ярлылыкны тутыру була. Бу китапта шагыйрьнең тәрҗемәи хәле, иҗатына багышланган мәкаләләр һәм шигырьләре урын алган. Шулай ук шагыйрь төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабының Хельсинкида 1953 елда «Төрки халык мәктәбе һимая җәмгыяте» тарафыннан Исмәгыйль Гарифулла хисабына бастырылуы турында мәгълүмат бар (3, 304). Ә 1967 елның апрелендә Хельсинкида «Габдулла Тукай җәмгыяте» эшли башлый.

Төркиядә Әхмәдвәли Мәңгәр оештырган «Казан төрекләренең культура вә ярдәмләшү берлеге» тарафыннан 1970-80 елларда Анкара һәм Истанбул шәһәрләрендә татар телендә чыгарылган әдәби-нәфис, сәяси һәм фәнни «Казан» журналының 1971 елгы март саны Габдулла Тукай иҗатына багышлана. Анда, шагыйрь иҗаты үрнәкләре белән бергә, тарихчы галим Надир Дәүләтнең «Казан төрекләре вә Габдулла Тукай» исемле күләмле мәкаләсе дә урын ала.

Күрүебезчә, татар мөһаҗирләре өчен Габдулла Тукай иҗаты аларны берләштерүче рухи маяк булып торган һәм хәзер дә шулай кала бирә. Алар тарафыннан чыгарылган басмаларда шагыйрь язмышын милләт язмышы белән бәйләү, иҗатыннан рухи куәт, илһам алу, аның белән юану чагылыш таба. Татар халкы дөньяның кайсы гына урынында гомер сөрмәсен, ул Тукайның рухы, моңы, шигырьләре, иҗаты белән яшәгән һәм яши.

Шунысын да әйтергә кирәк, Г.Тукай китаплары беркайчан да мәдәни,



▲ *«Балалар күңеле»*


▲ *«Күңелле сәхифәләр»*

фәнни кыйммәтләрен югалтмаячаклар. Чөнки, шагыйрьнең совет чорында басылган дүрт һәм биштомлыкларында шигырьләре билгеле бер сәяси режим тәэсирендә «иләнгәнлектән», кайбер милли, дини, сәяси мотивлар төшереп калдырылганлыктан, тарихи, әдәби чыганак буларак, гарәби язулы оригиналь китапларның әһәмияте бәһаләп бетергесез.

**Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фәнни хезмәткәре.*

## ӘДӘБИЯТ:

1. Гайнанов Р. Р. Татар вакытлы матбугаты (1905–1924): библиографик күрсәткеч = Татарская периодическая печать (1905-1924): библиографический указатель / Р. Р. Гайнанов, Р. Ф. Мәрданов, Ф. Н. Шәкүров. – Казан: Рухият, 1999. – 310 б.
2. Гыйләҗев Т. Ш. Җамал Вәлиди – «беренче тукайчы галим» / Т. Ш. Гыйләҗев // Җамал Вәлиди – энциклопедист галим: республика фәнни-гамәли конференциясе материаллары. – Казан, 2007. – Б. 73-82.
3. Кәримуллин Ә. Безнең кардәшлек: мәкаләләр / Ә. Кәримуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 335 б.
4. Тукай Г. Әсәрләр: 4 томда. 3 том / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976.
5. Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог: фәнни мәкаләләр җыентыгы. – Казан, 2008. – 192 б.

***Национальная библиотека Республики Татарстан вносит свой достойный вклад в сбор, изучение и хранение изданий Г.Тукая. В отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан сегодня хранятся 40 изданий (26 названий) его произведений.***

***Среди них:***

***– прижизненные издания;***

***– издания, опубликованные после его смерти;***

***– зарубежные издания;***

***– рукописные списки его сочинений;***

***– периодические издания с произведениями Г. Тукая.***

***Сочинения поэта пользуются огромной популярностью у читателей, не перестают быть объектом изучения ученых.***

# РОДНОЙ ЯЗЫК СПАСАЕТ ЖИЗНЬ

Все мы ещё со школьной скамьи знаем песню Г. Тукая «Туган тел». Мои родственники, когда собираются вместе, часто поют её. А ещё эта песня спасла жизнь моему дяде Сафиуллину Хатыпу во время Великой Отечественной войны. Но обо всём по порядку.

Моего дядю Сафиуллина Хатыпа призвали в ряды Красной Армии в 1939 году (до того он работал учителем). Когда началась война, он попал в плен. Четыре раза он пытался бежать, но его возвращали назад. Много испытаний пришлось пройти дяде в немецких лагерях. Семь раз его подвешивали за руки на целые сутки, а внизу бегали собаки (страшно подумать, что он испытал тогда!).

Телосложением он был похож на богатыря, физически очень здоров, так как до войны очень много занимался спортом. После войны, когда у него родились сыновья, дядя всегда им говорил, чтобы они занимались спортом, потому что, только благодаря спорту, он смог выжить в нечеловеческих условиях.

В 1943 году дядя Хатып попал в концлагерь, который находился в Норвегии. Там его приняли за еврея, а это означало одно: СМЕРТЬ! Но дядя ответил, что он татарин. И тогда один из служащих лагеря, который знал татарский язык, попросил его что-нибудь сказать на татарском. Дядя Хатып запел песню Г. Тукая «Туган тел». Служащий, как оказалось, тоже её знал. Так песня спасла моему дяде жизнь.

Мой дядя Хатып в концлагере был организатором и руководителем подпольной группы, также он имел связь с Движением Сопротивления норвежских коммунистов. В лагере военнопленные работали на заводе, оттуда они тайно выносили материал и из него делали себе оружие. Вскоре стало известно, что военнопленных должны были посадить в вагон смертников и там их уничтожить. Тогда мой дядя 3 мая 1945 года организовал восстание, и военнопленные сами себя освободили, помогли им и норвежские коммунисты. У дочери моего дяди есть материал, фотографии, газеты, подтверждающие эти факты. На одной из этих фотографий, мой дядя находится в центре вместе с теми, кто участвовал в восстании, на фоне лагеря. Есть и кинохроника, документы но только уже в архиве Министерства обороны.

Когда закончилась война, многих наших военнопленных отговаривали ехать на родину, пугали лагерями, репрессиями. Но дядя Хатып не побоялся, он собрал около тысячи наших военнопленных и сопровождал их в вагоне. Когда они ехали в поезде, у них были остановки и они выходили с поезда. На одной из таких остановок их увидел важный военный высокого ранга, который назвал их предателями. Тогда наши бывшие пленники сразу поникли. А на другой остановке проходил уже другой военный, он сказал другие слова: «Вы воевали как могли там, а мы – здесь». И сразу они воспряли духом.

На родине они попали в фильтровальный лагерь под Ленинградом. Там служил в штабе бывший ученик дяди, он сразу узнал его (тесен мир!). Вечерами они часто вели беседы. В лагере вся его группа в тысячу человек находилась около года. Их всех распустили по домам, никого не отправили в лагеря. А дядя дождался пока все его «подопечные» разъехались по домам и только в августе 1946 года он вернулся домой. Дома его не было 7 лет!

После войны он проработал 20 лет директором школы. Он – отличник народного образования РСФСР. Вырастил и воспитал четверых детей, все его дети – уважаемые и достойные люди!

Вот так Габдулла Тукай сыграл важную роль в жизни моего дяди – Сафиуллина Хатыпа Набиулловича.

**Гузяль ЭРКАЕВА,**
*ведущий библиотекарь с. Костенеево Елабужской центральной библиотеки Республики Татарстан*




# Габдулла Тукай китаплары Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларында

*«Бу кояш сүнсен, җиренә*
*мин кояш булмак телим.*
*Вакътыны йөртер кешеләр*
*ул заман миннән күреп…»*

XX гасыр татар әдәбиятында Г.Тукай зур урын тота. Шагыйрь кыска гына гомерендә дә татар шигъриятенең классик әсәрләрен тудырган. Үзенең иҗаты белән халык шагыйре исемен яулап алган. Г.Тукайның әдәби мирасы бик бай: 1905 елның азагыннан башланып, 1913 елның язында өзелгән җиде еллык иҗат дәверендә ул йөзләгән шигырь, дистәләп поэма, күпсанлы публицистик әсәрләр язып калдыра. Г.Тукай әсәрләре, шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турындагы әдәбият аерым китаплар булып та, җыентыкларда, вакытлы матбугат битләрендә дә татар, рус һәм башка халыклар телләрендә бик күп тапкыр басылганнар. 1956 елда Г.Тукай әсәрләре дүрттомлыгының дүртенче томы басылып чыга, анда шагыйрь әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның 1907 елдан 1956 елга кадәр булган библиографиясе бирелгән. 1956 елдан 1970 елга кадәр басылып чыкканнары, Л.Хәйдәрова һәм Н.Әхмәтҗанова тарафыннан төзелгән, 1974 елда Казан университеты нәшриятында басылган «Габдулла Тукай» исемле библиографик күрсәткечтә теркәлгән.

Татарстан Милли китапханәсе – татар китабын һәм Татарстан турындагы китапларны үзенә туплаучы, саклаучы, укучыларга җиткерүче иң зур китапханәләрнең берсе. Г.Тукайның үзе исән вакытта нәшер ителгән һәм гарәп шрифтында 1929 елга кадәр басылган китаплары китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана. Шагыйрьнең 1929-1938 елларда латин графикасында һәм 1939 елдан хәзерге көнгә хәтле чыккан китаплары, аның тормышы һәм иҗаты турындагы монографияләр, гыйльми конференция материаллары, альбомнар һ. б. документлар Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә тупланып барыла. Г.Тукай иҗатын укучыларга җиткерү бүлек эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе булып тора. Бүлекнең белешмә-библиографик аппараты фондны төрле яктан ачарга ярдәм итә: алфавит тәртибендәге һәм систематик каталогтан тыш китап фондына электрон каталог төзелгән. Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты турында җыентыкларда, газета-журналларда басылган мәгълүмат гадәти картотекада урын алган, 1994 елдан электрон картотекага теркәлеп алып барыла. Шагыйрь иҗаты белән кызыксынган һәр укучы монда үзенең соравына җавап таба ала.

Г.Тукай мирасын өйрәнүгә күп хезмәт куелган. Аның әсәрләренең аерым җыентыкларыннан тыш, бертомлык, ике томлык, дүрттомлык, биштомлык басмалары дөнья күрде. Укучылар игътибарына шагыйрьнең бүлектә саклана торган кайбер китаплары турында мәгълүматлар тәкъдим итәбез. Казанда «Яңалиф» нәшриятында 1929-1931 елларда Г.Тукайның 3 томлык әсәрләре җыелмасы басылган: 1 нче том 176 биттән, 2 нче том 189 биттән, 3 нче том 208 биттән тора. Басманы Фатих Сәйфи-Казанлы төзегән. 1938 елда шагыйрьнең 622 битле «Сайланма әсәрләр»е М.Җәлил редакциясендә басылып чыга. 1943 елда Г.Тукай «Әсәрләр»е академик басмасының беренче томы басыла. Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты әзерләгән бу томга шигырьләр, поэмалар тупланган, 472 биттән тора. Җыентык, аңа язылган сүз башы, сүзлекчә һәм искәрмәләр Якуб Агишев һәм Хәй Хисмәтуллин тарафыннан эшләнгән. Әсәрләрнең икенче томына Г.Тукайның проза әсәрләре тупланган, ул 1948 елда басылган, 568 биттән тора.

1955-1956 елларда беренче тапкыр Г.Тукай әсәрләре дүрт том итеп чыгарыла. Томлыкка кереш сүз язучы – Гали Халит, төзүчеләре – Хәй Хисмәтуллин һәм Якуб Агишев. Беренче, икенче томнарда шагыйрьнең шигъри әсәрләре, өченче, дүртенче томнарда чәчмә әсәрләре (прозасы)










тупланган. Дүрттомлыкта барлык әсәрләр дә хронологик тәртиптә бирелгән. Һәрбер томның ахырында искәрмәләр урнаштырылган.

Шагыйрь әсәрләренең 1975-1977 елларда чыккан дүрттомлыгында да томнарның бүленеше нигездә элекке дүрттомлыктагыча, әмма үзенең фәнни эшләнеше, тулылыгы белән аерылып тора. Бу дүрттомлыкка кертелгән әсәрләргә шагыйрьнең үзе исән чакта чыккан барлык басмалары буенча яңадан текстологик тикшерү үткәрелә. Төрле сәбәпләр аркасында элекке басмаларда киткән текст хаталары мөмкин кадәр төзәтелә. Беренчел чыганакларның да бер өлеше үзгәрә. Шунлыктан байтак әсәрләрнең язылу вакытлары ачыклана. Әсәрләрнең язылу һәм басылу даталары иске стильдә калдырыла. Бу дүрттомлыкка Г.Тукайның моңа кадәрге басмаларына кермәгән әсәрләре дә алына. Томнарны төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче – Рашат Гайнанов. Беренче томда шагыйрь турында кереш сүзне Сибгат Хәким язган.

1985-1986 елларда Габдулла Тукай әсәрләренең биштомлыгы беренче мәртәбә чыгарыла һәм шагыйрьнең тууына 100 ел тулуга багышлана. Беренче ике томга шигъри әсәрләр урнаштырылган, калган томнарда башка жанрларга урын бирелгән. Бу басмага Г.Тукайның дүрттомлыкларына керми калган һәм моңа кадәр аныкы икәнлеге ачыкланып җитмәгән яки билгеле булмаган әсәрләре дә кертелгән. Томнарны, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүче – Рашат Гайнанов. Текстларны хәзерләүдә Лена Гайнанова да катнашкан. Томнар Гали Халит редакциясендә чыга. Беренче томдагы кереш сүзне язучы да ул.

2009 елда 1000 данә тираж белән Г.Тукайның «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрде. Китапта шагыйрьнең гасыр кичкән иң яхшы шигъри һәм чәчмә әсәрләре, шулай ук аларның рус телендә дөнья күргән тәрҗемә үрнәкләре туплап бирелә. Китап 704 биттән тора. Аның төзүче–редакторы – Равил Рахмани. Биредә, фән һәм мәдәният оешмалары фондларында саклanучы фото һәм документаль материалларның төп нөсхәләреннән күчереп, бик күп иллюстрацияләр бирелгән. Фотоматериалларны җыеп, фотога төшереп, китапны бизәүче – Шамил Насыйров. Китап бик затлы итеп эшләнгән, «Таттрансгаз» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Рәфкать Кантюковның финанс ярдәме белән нәшер ителгән.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Г.Тукай әсәрләренең алты томлы тулы академик басмасы беренче мәртәбә әзерләнә. Аның 2011 елда 1 нче һәм 2 нче томнары басылып чыкты. 1 нче томга шагыйрьнең 1904-1908 елларда иҗат ителгән шигырьләре, балладалары, поэмалары, балалар өчен шигырьләре хронологик тәртиптә туплап бирелгән. Шулай ук Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр дә урын алган. Томны төзүчеләр, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр: Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авторлары: Н.Ш. Хисамов, З. З. Рәмиев; фәнни редакторы Зөфәр Рәмиев. 2 нче томда Тукайның 1909-1913 елларда иҗат ителгән шигъри әсәрләре бирелгән. Калган томнарында шагыйрьнең прозасы, публицистикасы, сатирик мәкаләләре, фельетоннары, әдәби тәнкыйте, балалар өчен язылган әсәрләре, очерклары, юлъязмалары һәм хатлары урын алачак.

Г.Тукай иҗатында балалар әдәбияты аеруча әһәмиятле бер тармак булып тора. Аның балалар өчен нәшер ителгән китаплары бик күп: алар аерым китаплар булып та, җыентыкларда да басылганнар. Мисал өчен, китапханәдә «Шүрәле» әкият-поэмасының аерым китап булып чыккан 20 басмасы саклана. 2006 елда чыккан китапта «Шүрәле» 15 телгә тәрҗемә




ителеп: татар, башкорт, үзбәк, уйгур, казакъ, төрек, фарсы, гарәп, таҗик, рус, венгр, инглиз, немец, француз, кытай телләрендә бирелгән. Бу китапның 2011 нче елда икенче басмасы да дөнья күрде. Китапларны рәссамнар Б.Әлменов, В.Булатов, А.Тимергалина, Н.Әлмиев, Р.Шәмсетдинов бизәгәннәр.

Г.Тукай әсәрләре рус һәм башка халыклар телләренә тәрҗемә ителгән. Аның рус телендәге беренче җыентыгы 1920 елда П.Радимов тәрҗемәсендә «Узюльган умид» («Разбитая надежда») исемендә дөнья күрә. Тууына 50 ел тулу уңае белән 1936 елда «Сайланма шигырьләр»е, 1960-1961 елларда ике томлык «Сайланма әсәрләр»е Казанда басылып чыгалар. Бүлектә шагыйрьнең рус телендә Казан, Мәскәү, Ленинград (Санкт-Петербург) шәһәрләре нәшриятларында басылган 40тан артык исемдәге китабы бар. Г.Тукай шигырьләрен рус теленә А.Ахматова, С.Липкин, Р.Моран, В.Тушнова, В.Ганиев, Р.Бохараев, В.Вәлиева һ. б. шагыйрьләр тәрҗемә иткәннәр. 2011 елда Татарстан китап нәшрияты һәм Мәскәүнең «Из века в век» Гуманитар башлангычлар халыкара агентлыгы Г. Тукайның «Яз фәйтуны = Фаэтон весны» исемле китабын бастырып чыгарды. Китап Мәскәү һәм Казанның иң яхшы шагыйрьләре-тәрҗемәчеләре тарафыннан әзерләнгән. Шигырьләр, балалар өчен әсәрләр, әкиятләр татар һәм рус телләрендә параллель рәвештә бирелгән. Күп кенә шигырьләр яңадан тәрҗемә ителгән. Китапка кереш сүзне Т.Галиуллин, ахыргы сүзне В.Широков язган. Г.Тукайның портретлары З.Гыймаев тарафыннан эшләнгән.

Китапханәдә шулай ук Г.Тукайның каракалпак, кыргыз, мари, төрекмән, үзбәк, чуваш, төрек, инглиз телләрендә аерым китаплары, Ә.Фәйзинең үзбәк телендәге «Тукай» романы, И.Нуруллинның төрек телендәге китаплары саклана.

Г.Тукайның тууына 125 ел тулуга багышлап Халыкара «ПЕН-клуб»ның «Татар ПЕН-үзәге», «Җыен» фонды «Идел-Пресс» нәшриятында шагыйрьнең атаклы өч әкиятен: «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык хикәясе», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»-ны татар, рус, төрек һәм инглиз телләрендә аерым китап итеп бастырып чыгарды. Шулай ук Татарстан китап нәшриятында Г.Тукайның Идел буе халыклары – татар, рус, башкорт, чуваш, удмурт, мари телләренә тәрҗемә ителгән шигырьләре тупланган җыентык дөнья күрде. Җыентыкны төзүче – Вакыйф Нуриев.

Г.Тукай иҗаты белән кызыксыну беркайчан да кимеми, аның иҗаты һәм шәхесе торган саен яңа яклары белән ачыла бара. Шагыйрьгә багышлап гыйльми конференцияләр, «Тукай укулары» үткәрәләр, иҗатын мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында өйрәнәләр, Г.Тукай музейлары оештырылган һәм эшли. Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре Тукай образына һәм иҗатына мөрәҗәгать итеп торалар – композиторлар Г.Тукай шигырьләренә музыкаль әсәрләр яза, рәссамнар Тукайны киндердә сурәтли, сынчылар һәйкәлсыннар коя һәм ясый. Ә язучылар һәм шагыйрьләр аңа үзләренең роман-повестьларын һәм шигырьләрен багышлый. Г.Тукай әсәрләрен укырга, өйрәнергә теләсәгез, китапханәгә рәхим итегез!

**Гөларам ЖОМАГОЛОВА,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге мөдире.*

***Национальная библиотека Республики Татарстан одна из крупнейших библиотек республики, занимающихся сбором и хранением, изучением и пропагандой наследия Г. Тукая.***

***Наиболее широко издания поэта и литература о нём представлены в отделе рукописей и редких книг и отделе татарской и краеведческой литературы.***

***Всестороннему раскрытию уникальных фондов библиотеки способствует справочный аппарат библиотеки включающий традиционные алфавитный и систематический каталоги, электронный каталог, тематические картотеки.***

***В статье рассматриваются наиболее интересные издания сочинений Г. Тукая и посвящённые ему материалы.***












# Һәр буынга яшьтәш Тукай

## (ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ КИЧӘ)

Татар халкының сөекле улы, әдип һәм шагыйрьнең тормыш юлын, бай иҗат мирасын киң җәмәгатьчелеккә дәгъватлауны максат итеп, 15 апрель көнне Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Зур уку залында, күргәзмәләр һәм мәдәни программалар бүлеге тарафыннан «Һәр буынга яшьтәш Тукай» дип исемләнгән әдәби-музыкаль чара уздырылды. Әлеге чараның 15 нче апрель көненә билгеләнүе дә очраклы гына түгел, чөнки нәкъ шул көнне 98 ел элек шагыйрьнең йөрәге тибүдән туктаган.

Фәнни эшләр буенча директор урынбасары Һадиев Ирек Габделхәй улы чараны тантаналы рәвештә ачып җибәрде. Ул килгән кунакларга Тукай шәхесенең, шагыйрь иҗат иткән рухи байлыкның еллар узган саен әһәмияте арта баруы турында сөйләде.

Тукай иҗаты вакыт сынавын үткән, аның шигырьләрен укып ничә буын тәрбияләнгән һәм тәрбияләнә, шунлыктан әлеге чарага төрле буын вәкилләре җыелган иде. Мини-спектакль рәвешендә барган кичәдә Казан шәһәренең татар театрлары артистлары һәм театр училищесы студентлары уйнады. Ә тамашачы, гадәттәгечә, карап, кул чабып кына утырмады, үзе дә катнашты.

Сценарий нигезендә шагыйрьнең театрга мәхәббәте, нинди мөнәсәбәттә булуы ассызыклап күрсәтелде. Һәм үткән гасырның танылган шәхесләре, Тукайның чордашлары: Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Фатих Әмирхан, Мәхмүт Галәү, Галиәсгар Камал истәлекләре, шулай ук шагыйрьнең үз шигырьләре кулланылды.

Артистлар кыска гына вакыт эчендә тамашачыны шул чорның мохитенә алып кереп, Тукай кичергән вакыйгаларны тоярга мөмкинчелек бирделәр. Әдип белән бәйле булган мизгелләрне чагылдырган слайд-шоу күренешләре, әлеге чараны тагын да тулыландырып торды.

Истәлекләрдән билгеле булганча, «Мөхәммәдия» шәкертләре, сөекле шагыйрьләренең хәлен белү өчен, 4 нче апрель көнне Клячкин больницасына барырга сүз куешалар һәм, аңа бүләк итү максаты белән, шагыйрьнең яраткан әсәрләреннән берсе – Толстойның «Хаҗи Морат» китабын әзерлиләр. Титул бите башында матур каллиграфия белән «Бөек шагыйребез Тукаевка ядкәр 1913» дип язылган була. Язылу датасы итеп, үзләре барасы көнне күрсәтәләр.

Кызганычка каршы, иске стиль белән 2 нче апрель көнне Тукайның йөрәге тибүдән туктый, шулай итеп әлеге бүләк үзенең хуҗасына ирешмичә кала. (Тапшырылмый калган бүләк/Ә. Кәримуллин. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – Б.499-501.)

Символик формада без, XXI гасыр яшьләре буларак, әлеге вакыйганы тормышка ашырырга уйладык.












Салмак кына музыка уйный, шул көй астында шагыйрь турында замандашлары тарафыннан әйтелгән истәлек сүзләре сөйләнә.

... Тукай кыска гына гомерендә күп язды һәм һичкайчан югалмый торган җәүһәрләр калдырды. Бүген, бары аның безнең арада йөргән көннәрен искә алып, артистларга булган мөнәсәбәтен һәм кешелек сыйфатларыннан кайбер детальләрне генә сөйләп үтәсебез килә.

– Тукай артистларны якын күрә һәм сәхнәне ярата иде. Ул үзенең шигырьләре белән артистларның җаннарына рухи азык бирә, безне тынычландыра торган иде.

– Үзенә күрә башка бертөрле кабатланмый торган нәфис табигатьле кеше иде Тукай. Ул эреләнми, кешелек горурлыгын да онытмый.

Ә бер көнне, дөресрәге, язның иң матур ае – апрель аеның 4 числосында, без, артистлар, Тукайның туган көненә барырга булдык. (Музыка тына).

– Җәмәгать, туган көнгә бит буш кул белән барып булмый.

– Нәрсә бүләк итәбез?

– Шәхси китапханәсенә берәр китап бүләк итик, безнең истәлегебез булсын.

– Ә нинди китап?

– Тукай өчен Толстойның «Хаҗи Морат» китабы зур сөенеч булыр иде. Беренчедән, ул аның яраткан әдибе, икенчедән, Казанда басыла, шуның өстенә, әле ул дөньяга да чыгып җитмәгән, иң беренчеләрдән булып остазыбыз кулында булачак.

– Я, кая соң китабың?

— (Йөгереп керә) Өлгердем, өлгердем! Әле генә басмаханәгә барып, махсус Тукай әфәнде өчен әсәрне яхшы кәгазьгә бастырып чыгардым!

– Әйдәгез, истәлеккә берәр нәрсә языйк.

– Бик дөрес, ә нәрсә диеп язарбыз соң?

– «Истәлек өчен Габдулла әфәндегә!»

– Юк инде, ничектер башкачарак кирәк, мисал өчен: «Терелүегезне теләп калабыз!» – дисәк?

– Җәмәгать, «Татар яшьләре тарафыннан бөек шагыйребез Тукаевка ядкәр.» – ничек яңгырый?

– (Барысы да бергә): Афәрин, бик хуп булыр!

«Бәйрәм бүген» җыры башкарыла.

Шәкертләрнең Г.Тукай янында булулары күренеше. Шәкертләр һәм Тукай.

– Туган көнегез белән, Тукаев Әфәнде!

– Рәхмәт, дусларым!

– Тукай әфәнде, без бит синең янга буш кул белән килмәдек, менә, бездән шушы китапны бүләк итеп алыгызчы! (Бүләкне тапшыралар)

Тукай, китапны караганнан соң, чын күңеленнән шатланып:

– Ихластан күңелемне күрдегез, дусларым! Яраткан әдибемнең иң яраткан әсәре минем өчен зур сөенеч булды, рәхмәт барыгызга да!

*(«Китап» шигыре укыла)*

Һич тә күңелем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны





Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;
Хәсрәт соңра уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгылып- сыгылып елаган яшь, —
Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.

Тукай бик яшь килеш дөньякүләм танылган шагыйрь булган. Бер гасырдан артык вакыт узуга карамастан, бүгенге замана яшьләре дә Тукайны шул дәрәҗәдә кабул итәргә тиеш. Шуны ассызыклап, чарада Тукайның «Су анасы» шигырен, мәктәп укучысы оста итеп башкарды.

Кичә, артистлар һәм тамашачылар белән берлектә, «Туган тел» җырын җырлап тәмамланды.

Габдулла Тукай иҗатына, әсәрләренә битараф булмаучылар күңеленә әлеге кичә хуш килде. Кичәгә килгән тамашачылардан: «Килүебез юкка булмаган икән!» – дигән сүзләрне ишеткәч, Тукай иҗаты буыннан-буынга калып, аның җанлы исеме мәңгегә онытылмаячагына күңелебез инанды.


**Фирдәвес ИМАМОВА,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсе күргәзмәләр һәм мәдәни программалар бүлегенең әйдәп баручы китапханәчесе*

**Акйолдыз ФӘЙЗОВА,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсе күргәзмәләр һәм мәдәни программалар бүлеге китапханәчесе*




***15 апреля 2011 года в Национальной библиотеке Республики Татарстан состоялся литературно-музыкальный вечер «Всегда современный Тукай». Вечер открыл заместитель директора библиотеки по научной работе И. Г. Хадиев, рассказавший о значении наследия Г. Тукая для современного и будущего поколений.***

***Кульминацией вечера стал миниспектакль, поставленный артистами татарских театров г. Казани и студентами Театрального училища.***



# Торжества по случаю 125-летия со дня рождения Габдуллы Тукая в Донской государственной публичной библиотеке

В Ростовской области проживают представители более ста национальностей. Благодаря системе эффективного регулирования отношений с представителями национально-культурных общественных организаций в Ростовской области на протяжении многих лет устойчиво сохраняется стабильная и прогнозируемая межэтническая ситуация. Многонациональность – историческая характеристика нашего региона.

Библиотеки области ведут активную работу по сохранению и развитию культур, языков, традиций народов, живущих на Дону, расширению сотрудничества и духовному взаимообогащению граждан всех национальностей.

Одной из особенностей работы библиотек с национальными группами является библиотечное обслуживание этнических групп, адаптировавшихся на Донской земле, тех, кто давно живет и трудится вместе с другими народами на Дону, воспринимает его культуру, образ жизни. Это армяне, татары, евреи, немцы, поляки, грузины, народы Северного Кавказа, корейцы и другие.

Национально-культурные объединения этих этнических групп активно возрождают культуру, традиции, язык и сотрудничают с учреждениями культуры и библиотеками. Например, Ростовская городская общественная организация Татарский культурный центр (ТКЦ) «Якташлар» во главе с Батгутдиновым Марселем Расимовичем ведет свою деятельность в тесном контакте с библиотеками города Ростова-на-Дону,




в том числе и с Донской государственной публичной библиотекой.

В библиотеке неоднократно проводились мероприятия, посвященные развитию татарской культуры в Ростовской области, где выступали приглашенные из Казани артисты. Одним из таких мероприятий был литературный вечер, посвященный 120-летию Габдуллы Тукая.

В этом году центр «Якташлар» организовал литературный праздник «125-летие со дня рождения Габдуллы Тукая», который также состоялся в Донской государственной публичной библиотеке. Сотрудники библиотеки подготовили к празднику большую развернутую выставку литературы о жизни и творчестве Габдуллы Тукая.

На сцене, оформленной флагами России, Татарстана и Ростовской области, выступили докладчики, певцы, танцоры, музыканты.

Гостей и участников встречали традиционным татарским угощением чак-чак девушки в национальных костюмах. Звучал гимн Республики Татарстан.

Открыл праздник председатель ТКЦ «Якташлар» Бадгутдинов Марсель Расимович, который поздравил присутствующих с праздником.

Заместитель директора Донской государственной публичной библиотеки Мун Михаил Енсонович от имени администрации и коллектива библиотеки произнес на татарском языке следующее поздравление: «Салям алейкум, хурмэтлэ татар миллэтэ вэкиллэрэ! Хурмэтле туганнар! Бэзнэн Дон дэулэт жэмэгат китапханэсе идарэсе хэм хэзмэткэрлэре исэмэннэн Сезнэ буйек татар халык шагыйрэ Габдулла Тукайнын тууына йоз йегермэ биш йыл тулуга багышланган тантаналы



▲ *Дон дәүләт җәмәгать китапханәсе бинасы.*



▲ *Китапханәнең эчке күренеше.*

кичэ белэн тэбрик итэм. Мин белэм – сэз барыгыз да Тукайны яратасыз!

Яратмыйча булмый, чонки ул зур талант иясэ булган, матур-матур эсэрлэр язып калдырган. Анын ижаты русларнын Пушкины белян янэшэ торырлык. Тукайнын ижаты улемсэз. Аны укыгыз, яратыгыз, балаларыгызга да ойрэтегез, мирасын кадерлэп саклагыз!

Тукайлы миллэт – буйек миллэт! Сезнэн телегез дэ бик матур янгырашлы. Рэхмэт!». (Это поздравление помог ему составить заместитель директора Национальной библиотеки Республики Татарстан Хадиев Ирек Габделхаевич).

О жизни Габдуллы Тукая рассказал Деветьяров Хашим Лутфуллович, который неоднократно посещал музей Тукая, побывал во всех городах и деревнях, где жил и работал великий писатель, собрал много материалов о Габдулле Тукае. Бадгутдинов Марсель исполнил песню «Аллага шокер».

Юная участница праздника Алина Фахрутдинова прочитала стихотворение «О свободе».

Ветеран войск специального назначения Мамлеев Азизулла Мусянович исполнил на мандолине композицию, посвященную Г. Тукаю.

Хореографический коллектив «Алтын» г. Ростова-на-Дону дебютировал с танцем «Бэхеткэ-шатлыкка». Лилиана Зайниева исполнила песню «Белая черемуха».

Ростовская поэтесса Фахрутдинова Салимя Исмагиловна прочитала стихотворение, сочиненное ею специально к празднованию 125-летия Габдуллы Тукая. Ансамбль восточного танца «Девадайси» исполнил композицию «Дею Дей». Затем выступила серебряный призер открытого первенства по художественной гимнастике Аксайского района Алина Бадгутдинова. После выступлений артистов был показан мультфильм по мотивам стихотворения Г. Тукая, а также фильм-воспоминание о жизни великого поэта.

До самого закрытия библиотеки не прекращались зажигательные татарские танцы.

**Михаил МУН,**
*заместитель директора*
*Донской государственной*
*публичной библиотеки*

***Ростов өлкәсендә йөздән артык милләт вәкилләре дус һәм тату гомер кичерәләр, аларны тарихи, мәдәни, этник бәйләнешләр берләштерә. Мәдәни чараларны үткәрүдә өлкә китапханәсенең роле зур. Ростов шәһәренең «Якташлар» исемле Татар мәдәни үзәге белән Дон шәһәренең дәүләт җәмәгать китапханәсе кулга-кул тотынып, татар әдәбияты, сәнгатенә багышланган күптөрле чаралар үткәрделәр. Шуларга мисал итеп татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулуга багышлап үткәрелгән кичәне күрсәтергә була. Ә быел исә «Якташлар» үзәге, Дон дәүләт җәмәгать китапханәсе белән берлектә, «Габдулла Тукайның тууына 125 ел» дигән әдәби бәйрәм оештырды. Биредә бөек шагыйрь әсәрләреннән оештырылган китап күргәзмәсе дә күпләрнең игътибарын җәлеп итте.***

***Россия, Ростов өлкәсе һәм Татарстан флаглары белән бизәлгән сәхнәдә докладчылар, җырчылар, музыкантлар, биючеләр чыгыш ясады.***

***Кунакларны милли киемнәр кигән татар кызлары татарның бәйрәм күчтәнәче чәк-чәк белән каршы алдылар. Татарстан Республикасы гимны яңгырау ямь өстенә ямь булды.***

***Бәйрәмне ачуда «Якташлар» татар мәдәни үзәге рәисе Бәдгытдинов Марсель Рәсим улы һәм Дон дәүләт җәмәгать китапханәсенең директор урынбасары Мун Михаил Енсонович катнашты.***

***Бөек шагыйребезнең олуг юбилеена багышланган тантана бик озак дәвам итте һәм тамашачылар күңелендә онытылмаслык эз калдырды.***

# Тел язмышы безне дә борчый

Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып соңгы сулышына кадәр сүз һәм тел аның аерылгысыз юлдашы булып тора. «Туган тел» дип һәр кеше хөрмәт белән әйтә.Үзенең туган телен яраткан кеше генә башка телләрне дә үз итә.

Хәзерге вакытта җир шарында 5 меңнән артык тел барлыгы билгеле. ЮНЕСКО раславынча, дөньяда киң таралган 14 тел арасында татар теле дә бар. Болар гарәп, рус, немец, инглиз, француз, итальян, испан, португал, кытай, япон, урду, бенгал, һинд һәм татар телләре. Бу, әлбәттә, безгә горурлык өсти. Ләкин без вакыт бөтен нәрсәне үзгәртеп торган заманда яшибез. Егерме беренче гасыр да тормышыбызга зур яңалыклар алып килде. Дөньяда глобальләшү процессы бара: Интернет, компьютер, телевидение тел язмышына тискәре йогынты ясыйлар. Мондый шартларда халыкның аңын, милли мәдәниятен саклау аеруча кирәк. Дөрес, тел язмышы күпләрне борчый. Чөнки тел бетсә – милләт тә бетә. «Тел халыкның акылын, гореф-гадәтен, дөньяга карашын, фәлсәфәсен, тарихын, кыскасы, бөтен күңел байлыгын мең еллар буенча үзенә сеңдереп килеп, безнең заманнарга җиткергән чиксез хәзинә» – дип язган иде Гомәр ага Бәширов. Бу сүзләрнең хаклыгын китапханәчеләр яхшы аңлый.

Милләтнең саклануы да турыдан-туры телгә бәйле. Чөнки гыйлем алу, аңны үстерү, җиһанны танып белү һәм аралашу туган тел аша тормышка ашырыла. Милләтнең сакчысы булган ана телен, аның байлыгын, канунашларын саклау, үстерү – һәркемнең бурычы. Ата-анасы татар булган балага татарча белү, уку мәҗбүри итеп каралырга тиеш.

Кеше үзенә аралашу өчен иң гади чараны эзли. Күп вакыт бу гади чара туган тел файдасына түгел. Зыялы кеше төрле йогынтыларга карамыйча туган телен сак-












ларга тырыша. Татарстан Республикасының телләр турындагы Законын кабул итү, татар теленең кулланылышы киңәюгә, аны өйрәнүчеләрнең һәм белүчеләрнең артуына, телнең үсүенә уңай йогынты ясады. Соңгы вакытта татар теленә игътибар арту безне, китапханәчеләрне, куандыра. Милли китапханәнең Вакытлы матбугат бүлеге хезмәткәрләре татар телен пропагандалау – тормыш таләбе икәнлеген яхшы аңлыйлар. Без китап укучыларга рус һәм татар телләрендә хезмәт күрсәтәбез. Укучыларны татар телендә чыккан язма әсәрләр белән таныштырабыз. Китапханә хезмәткәрләре, туган телне өйрәнүгә кызыксыну уяту кирәклеген аңлап, студентларга татар телендә чыгучы газета-журналларны тәкъдим итә.

Вакытлы матбугат бүлегендә уздырылган чаралар – экскурсияләр, күргәзмәләр, укучылар белән очрашулар, газета-журналларга күзәтүләр – болар барысы да ике телдә алып барыла. Ана телендә бирелгән мәгълүмат кеше тарафыннан яхшырак үзләштерелә, аның йөрәк түренә тирәнрәк үтеп керә. Телне тергезү, саклау һәм үстерүнең юлы бер – телне даими куллану. Кулланылышта булган тел генә үсә, шомара. Телне гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәпләрдә, махсус уку йортларында, эш урыннарында куллану кирәк. Без, китапханәчеләр, татар теленең мөмкинлекләрен ачыклап, аның заманча танып белү ысулы икәнен, киләчәге өметле булуын күрсәтә алабыз. Телне саклау һәм үстерү, аны алдынгы телләр сафына кертү – туган телнең көченә, бөеклегенә, якты киләчәгенә ышану барыбызга да кирәк. Кешелек дөньясы һаман алга бара, үзенең алдына торган саен зуррак максатлар куя, күбрәк белергә, аңларга, булдырырга тели. Татар халкы да шуңа омтыла. Милли мәдәниятне күтәрүдә телнең роле искиткеч зур. Бөек шагыйребез татар телен үстерүгә зур өлеш кертте, аңа мәхәббәт тәрбияләде. Халык шагыйренең сүзләре бүген дә заманча яңгырый:

*«И туган тел, и матур тел, әткәм, әнкәмнең теле*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*
*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.»*

**Халидә БОРҺАНОВА,**
*Татарстан Республикасы*
*Милли китапханәсенең вакытлы*
*матбугат бүлеге китапханәчесе*




*По данным ЮНЕСКО, татарский язык вошёл в число 14 самых распространенных на земле языков. Автор статьи выражает свою обеспокоенность за сохранение и дальнейшее развитие татарского языка и отмечает особую роль в этом библиотеки.*

*2011 год, объявленный Годом Г. Тукая, – это ещё одна возможность воспеть красоту родного татарского народа.*

ЮБИЛЕЙЛАР
ЮБИЛЕИ

Республикабызның төрле шәһәр-районнарындагы китапханәләр системаларын һәм Үзәк китапханәләрне җитәкләүче һөнәрдәшләребезне әле күптән түгел булып узган һәм якын арада булачак күркәм юбилейлары белән котлыйбыз. Югары дәрәҗәдәге эшчәнлегегез, җитәкчелек таланты, шулай ук әһәмиятле мәсьәләләрне дәүләт югарылыгында хәл итә белү осталыгы Сездә җитди мәсьәләләрне чишкәндә өстенлекле якларны төгәл билгеләү һәм булган фондлардан тиешенчә файдалана белү сыйфатлары белән тыгыз үрелгән. Гаҗәеп дәрәҗәдәге һөнәри намуслылык, таләпчәнлек, максатчанлык – Сезнең эш стилен билгеләүче төп сыйфатлар булып тора. Сайлаган юлыгызда киләчәктә дә уңышларга ирешүегезне, билгеләнгән планнарыгызның тормышка ашуын һәм, әлбәттә инде,



үзегезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет, иминлек, күтәренке кәеф, рух ныклыгы, иҗади хезмәт дәрте һәм китапханәләребезне яңа үрләргә күтәрүдә уңыш-казанышлар телибез. Әлеге бәйрәмдар затларыбызның исемнәрен атыйк:

Чистай Үзәк китапханәсе директоры **Байбикова Гөлйөзем Әхмәт кызы**;

Апас Үзәк китапханәсе директоры **Шәфигуллина Гөлзада Абдулла кызы**;

Актаныш Үзәк китапханәсе директоры **Мәүлетова Энже Мулланур кызы**;

Арча Үзәк китапханәсе директоры **Фазылова Лилия Рәфыйк кызы**;

Сарман Үзәк китапханәсе директоры **Тимербаева Фәридә Каюм кызы**.

*Иң изге теләкләр һәм зур ихтирам белән:*
*Татарстан Республикасы*
*Милли китапханәсе җитәкчелеге.*

ВАКЫТ- ВАКЫЙГА
ХРОНИКА

# Азатлык һәм гаделлек җырчысы

Татар халкының бөек улы бик бай иҗади мирас калдырды һәм гомум халык тарафыннан зур хөрмәт, дан-шөһрәт яулады. Габдулла Тукайның әсәрләре төрле телләргә тәрҗемә ителгән, алар зур тиражлар белән басылалар. Аның иҗаты музыкаль әсәрләр иҗат итү өчен дә саекмас чыганак булып тора. Шагыйрьнең туган көнендә һәр ел саен Татарстанның шәһәр һәм районнарында танылган язучылар, шагыйрьләр һәм меңләгән шигърият яратучылар катнашында Шигырь бәйрәмнәре уза.

Шагыйрь образы татар әдәбиятында киң чагылыш таба. Шагыйрьләр, язучылар һәм әдәбият белгечләре Г. Тукайга багышлап әсәрләр иҗат итәләр, гыйльми хезмәтләр язалар. Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына караган тирәнтен эзләнүләр алып баралар, иҗади һәм рухи биографиясеннән яңа фактлар ачалар.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә, Габдулла Тукайның юбилеена багышлап, «Азатлык һәм гаделлек җырчысы» дип аталган күргәзмә ачылды. Аның төп максаты – шагыйрь шәхесе һәм иҗаты турында мөмкин кадәр тулы мәгълүмат бирү.

Күргәзмәгә Милли китапханә фондларында булган китаби басмалар һәм кайбер электрон басмалар куелган. Бу – Габдулла Тукайның үзен һәм үз чорын чагылдырып төрле жанрларда иҗат иткән әсәрләре (шигырь, проза, автобиографик проза, хатлар…). Күргәзмәдә сирәк очрый торган, 1909-1913 нче елларда гарәп шрифтында һәм 1930-1940 нчы елларда латин графикасында чыккан китаплар да урын алган. Шулай ук шагыйрь әсәрләренең инглиз, төрек, алман, украин, кытай һәм башка телләргә тәрҗемәләре белән дә танышa аласыз. Шагыйрь иҗаты һәм тормыш юлы турындагы әдәбият та Тукай иҗатын яратучылар өчен кызыклы һәм файдалы булачак. Күргәзмә әдәбият белгечләренә, әдәбият укытучыларына, студент-филологларга һәм Г. Тукай иҗатын яратучыларга тәкъдим ителә, шулай ук китапханә хезмәтләреннән файдаланучыларның да күбесе аны игътибарларыннан читтә калдырмас.

Әлеге экспозиция Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлекләре хезмәткәрләренең уртак хезмәте нәтиҗәсе булып тора.

**Фәйрүзә ВӘЛИЕВА,**
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегенең хезмәт күрсәтү бүлекчәсе мөдире*

# «И мөкатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз...»

## Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН (1886-1913)

**Татар халкының мәшһүр улына бу дөньяда бары тик егерме җиде генә ел яшәү насыйп була. Кыска гомер юлы үтсә дә, ул янып-ялкынланып иҗат итә: йөзләгән шигырь, дистәләп поэма, күпсанлы публицистик әсәрләр яза. Аның иҗатын, һич арттырмыйча, XX йөз башы милли чынбарлыгының энциклопедиясе дип атарга мөмкин. Шагыйрь каләме татар мәдәнияте тарихына иң матур, иң якты сәхифәләр язып калдырды.**

**Безнең балалар әдәбиятыбызның елга башында да Габдулла Тукай тора. Ул нәниләр өчен, берсеннән-берсе гүзәл дистәләгән әсәрләр иҗат итә. Аның «Шүрәле», «Су анасы» поэмалары, «Кәҗә белән Сарык хикәясе», «Алтын әтәч», «Бала белән Күбәләк», «Карлыгач», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре» һ.б. шигырьләре татар балалар әдәбиятының алтын фондын тәшкил итәләр. Аларда татар милләтенең дистәләгән буын нәни балалары тәрбияләнеп үскән.**

**Бу библиографик күрсәткеч урта һәм өлкән сыйныф укучылары өчен тәкъдим ителә. Ул ике бүлектән тора. Беренче бүлеккә Габдулла Тукайның балалар өчен иҗат иткән иң яхшы әсәрләре тупланган китаплар кертелгән. Икенче бүлектә бөек шагыйребезнең иҗат һәм тормыш юлын яктырткан, аның иҗатының дөньякүләм танылганлыгын һәм зур тәэсиргә ия булуын исбатлап торучы әсәрләр тупланган китаплар урын алган.**

## ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫНЫҢ ТӨП ДАТАЛАРЫ

(ДАТАЛАР ИСКЕ СТИЛЬ БЕЛӘН БИРЕЛӘ)

▶ **1886.** 14 апрель – Габдулла Казан губернасы Казан өязе Кушлавыч авылында (хәзерге Әтнә районы) указлы мулла Мөхәммәтгариф гаиләсендә дөньяга килә.

▶ **29 август** – Әтисе Мөхәммәтгариф вафат була.

▶ **1890. 18 гыйнвар** – Әнисе Бибимәмдүдә вафат була.

▶ **1891-1892** – Габдулла Казанның Яңа Татар Бистәсендә кәсепчелек белән көн күрүче, башка баласы булмаган Мөхәммәтвәли гаиләсендә яши.

▶ **1892. Июнь** – Габдулланы Кырлайга алып киләләр. Аны шушы авылның Сәгъди исемле кешесе асрамага ала.

▶ **1893. Октябрь** – Мәдрәсәдә укый башлый.

▶ **1894. Декабрь** – Габдулла Уральски (Җаек) шәһәренә килә.

▶ **1895-1899** – «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый башлый, өч еллык рус классын тәмамлый.

▶ **1905. Җәй** – «Уралец» газетасы типографиясендә хәреф җыючы булып эшли.

▶ **1906. Гыйнвар** – «Әл-гасрел-җәдит» журналының беренче саны чыга. Г. Тукай бу журналның җаваплы сәркятибе. Үзенең беренче шигырьләре дә шушы журналда басылып чыга.

▶ **Июнь** – Уральскида татар телендә беренче сатирик журнал «Уклар»ның беренче саны чыга. Редакциядә төп эшне Г. Тукай алып бара.

▶ **1907. Февраль** – рәсми рәвештә редакциядәге эшеннән чыгарыла.

▶ **Җәй** – «Шүрәле» поэмасын яза.

▶ **Октябрь** – Уральскидан Казанга килә.

▶ **Ноябрь** – Тукай «Әл-ислах» газетасында эшли башлый. «Г. Тукаев шигырьләре» дигән беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә.

▶ **1908** – Г. Тукай «Китап» нәшриятында корректорлык эшен дәвам итә.

▶ **Август** – Казанда рәсемле сатирик «Яшен» журналының беренче саны чыга, Г. Тукай аның җаваплы сәркятибе була.

▶ **Октябрь** – «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын язып тәмамлый һәм әсәр аерым китап булып басылып чыга.

▶ **1909. Гыйнвар** – «Габдулла Тукаев диваны» исеме белән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

# 1 бүлек

# Г.Тукай әсәрләре

▶ **Җәй** – Сембер губернасында фабрикант Акчуриннарда кунакта була.

▶ **Сентябрь** – мәктәпләрдә әдәбият укыту өчен үз әсәрләреннән хрестоматия формасында төзелгән «Яңа кыйраәт» исемле китабы басылып чыга.

▶ **1910. Март** – Казанда рәсемле сатирик «Ялт-йолт» журналының беренче саны басылып чыга. Г. Тукай аның җаваплы сәркятибе була.

▶ **1911. Март** – «Күңел җимешләре» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

▶ **Апрель** – Әстерханга шагыйрь Сәгыйть Рәмиев янына бара.

▶ **Сентябрь** – Тукай тарафыннан төзелгән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән китап-хрестоматия басылып чыга.

▶ **1912. Февраль** – сатирик һәм юмористик шигырьләрен туплаган «Яшен ташлары» исемле китабы басылып чыга.

▶ **Апрель** – Тукай үзенең соңгы сәяхәтенә чыгып китә. Башта Уфага, анан Петербургка бара.

▶ **Май** – яңадан Уфага килә. Кымыз белән дәвалану өчен Троицк шәһәре янындагы казакъ даласына китә.

▶ **Декабрь** – «Җан азыклары» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

▶ **1913. Гыйнвар-февраль** – «Кояш» газетасында һәм «Аң» журналында әледән-әле әсәрләре чыгып тора. Бертомлык әсәрләр җыентыгын әзерләргә керешә. Авыруы көчәя.

▶ **Февраль** – Тукай Казанның Клячкин хастаханәсенә кереп ята.

▶ **Март** – Бертомлыгын әзерләү эшләрен дәвам иттерә. Соңгы шигырьләре һәм фельетоннары иҗат ителә.

▶ **2 апрель.** 20 сәг. 15 мин. – Тукай вафат була.




Тукай Г. Бала белән Күбәләк: шигырьләр, әкиятләр / Г. Тукай; Й. Вәлиәхмәтов һәм В. Булатов рәс. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 78 б.

Бу китапка сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның балалар өчен язган бик матур, шаян шигырьләре һәм әкиятләре тупланган. Аларның һәммәсенә искиткеч матур рәсемнәр ясалган.




Тукай Г. И мөкатдәс моңлы сазым…: шигырьләр / Г. Тукай. – Казан: Мәгариф, 1999. – 143 б. – Текст парал. татар, рус.

Тукайның бөтен иҗаты үзе кебек гел яшьлектән тора. Тукай шигырьләрендә гүя кыска яшьлек, өзелеп калган гомер хисабына котырып ага торган, күңелләрне сафландырып, нурландырып уза торган ниндидер яшерен көч бар. Бу китапта Тукайның лирик шигырьләре тупланган.




Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре / Г.Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 160 б.

Әлеге китап бөек татар шагыйре Г. Тукайның мәктәп-мәдрәсәләр өчен төзелгән мәгълүм дәреслек-хрестоматиясе (1911) нигезендә кабат бастырыла.

Биредә Тукайның үз шигырьләре белән беррәттән Каюм Насыйри, Гаяз Исхакый, Дәрдмәнд, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Фатих Кәрими, Ризаэтдин Фәхретдин һ. б. дистәдән артык күренекле татар әдипләренең гүзәл әсәрләре тупланган.




Тукай Г. Безнең гаилә /Г. Тукай; төз. Н. Газизова; рәс. Т. Хаҗиәхмәтов. – Казан: Раннур, 2001. – 176 б.

Габдулла Тукайның балалар өчен язган шигырьләре, хикәяләре, мәсәлләре матур иллюстрацияләр белән бирелгән.




Тукай Г. Мәсәлләр / Г. Тукай; рәссамы И. Колмогорцева – Казан: Мәгариф, 2002. – 46 б.

Рәсемнәр белән матур итеп эшләнгән бу китапта Г. Тукайның балалар өчен язган тирән мәгънәле мәсәлләре тупланган. Һәрбер мәсәлдән соң аның төп мәгънәсен аңлаткан кыска гына йомгаклау җөмләсе бирелгән.

Тукай Г. Эш беткәч уйнарга ярый: шигырьләр / Г. Тукай. – Казан: Мәгариф, 2002. – 46 б.




Бу китапта балаларның яраткан шагыйре Г. Тукайның иң матур шигырьләре тупланган. Китап бишектән ишетеп үскән «Туган тел» шигыре белән башланып, «Кызыклы шәкерт», «Сөткә төшкән тычкан» кебек шаян шигырьләр белән дәвам итә һәм бик тирән мәгънәле «Япон хикәясе» белән тәмамлана.

Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.



1 т. Шигырьләр, поэмалар / төз.: Н. Хисамов, З. Мөхәммәтшин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 271 б. Күренекле шагыйребез Г. Тукайның 1905 елдан алып 1913 елга кадәр иҗат иткән шигырьләре, поэмалары хронологик тәртиптә бирелгән.



Тукай Г. Кәҗә белән Сарык әкияте /Г. Тукай. – Казан: Мәгариф, 2005. – 47 б. – Текст парал. татар, ингл., рус.

Искиткеч матур рәсемнәр белән бизәкләп эшләнгән бу әкият китабы татар телендә һәм инглиз, рус телләренә тәрҗемә итеп бирелгән. Рәсемнәрне 7-8-10 яшьлек балалар ясаган.




2 т. Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар /төз.: Э. Галимҗанова, З. Шәйхелисламов, З. Рәмиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 383 б.

Бу китапка Г. Тукайның 1906 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр язылган мәкаләләре, истәлекләр һәм кульъязмалар кертелгән. Тукайның туганнарына, дусларына, каләмдәшләренә язган хатлары тупланган.

Тукай Г. Шүрәле / Г. Тукай; төз. Ф.Әхмәтова-Урманче, Р. Корбан; Б. Урманче рәс. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 78 б.




Тукаебызның бөтен дөньяга танылган Шүрәле әкияте игътибарны җәлеп итә торган рәсемнәр белән эшләнгән китапта татар, башкорт, үзбәк, уйгур, казах, төрек, фарсы, гарәп, таҗик, рус, венгр, инглиз, немец, француз һәм кытай телләрендә бирелгән.

Тукай Г. Печән базары яхуд яңа Кисекбаш: поэма / Г. Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 31 б.




Г. Тукайның биш көн эчендә язылып беткән бу тирән мәгънәле поэмасы тормыштан алынган вакыйгаларны сурәтли. Кисекбаш поэмасы Печән базары өчен типик булган сәүдәгәрләр, кадимчеләр һәм фанатикларны чагылдырган гомуми персонаж. Поэманың төп герое Кисекбаш. Аның хатынын һәм улын урлап, үзен гәүдәсез итүче Дию. Кисекбашка ярдәм итүче Карәхмәт – Никитин циркы көрәшчесе, реаль кеше.



Тукай Г. Сагыныр вакытлар: балалар өчен шигырьләр, шигъри әкиятләр, автобиографик повесть/ Г. Тукай. – Казан: Мәгариф, 2006. – 207 б.: рәс. б-н. – Текст парал. татар, рус.

Бу китап 3 бүлектән тора, татар һәм рус телләрендә язылган.

1 бүлектә – шигырьләр, 2 бүлектә – шигырьгә салган әкиятләр, 3 бүлектә – «Исемдә калганнар» автобиографик повесте.



Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр / Г. Тукай; төз. һәм кереш сүз авторы Ф. Бәшир.– 2нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 479 б.

Китапта татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның иң яхшы шигырьләре, поэмалары, мәкаләләре, истәлекләре, юльязмалары, мәсәлләре һәм балалар өчен язган хикәяләре урын алган.

# 2 бүлек
# Язучылар һәм шагыйрьләрТукай турында




**Мин Тукайга киләм: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 192 б.**

Сөекле шагыйребез Г. Тукайның 110 еллык юбилее уңае белән чыгарылган бу җыентыкка татар һәм башка тугандаш халыклар шагыйрьләренең аңа атап язган иң яхшы әсәрләре туплап бирелгән.

Татар шагыйрьләре бүлеге Х. Туфан, Н. Арсланов, Ә. Ерикәй, Г. Афзал һәм башкалар, ә тугандаш халыклар һәм чит ил шагыйрьләре бүлеге итальян язучысы Джованни Жерманеттоның «Туры Тукай» шигыре белән башланып китә. Бу бүлеккә рус, башкорт, чуаш, әзербайҗан, яһүд, украин, казакъ, гыйрак шагыйрьләренең әсәрләре кертелгән.




**Нуруллин И. Моңлы саз чыңнары: документаль роман / И. Нуруллин.– Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 272 б.**

